# ТАТАР МИФЛАРЫ – БАЛАЛАРГА

# ТАТАРСКАЯ МИФОЛОГИЯ ДЛЯ ДЕТЕЙ



# ТАТАР МИФЛАРЫ – БАЛАЛАРГА

# ТАТАРСКАЯ МИФОЛОГИЯ ДЛЯ ДЕТЕЙ

Казан. Татарстан китап нәшрияты. 2018
Казань. Татарское книжное издательство. 2018

УДК 821.1/.8-34
ББК 84(0)-4
Т23

Автор-төзүчесе Галимҗан Гыйльманов

Ольга Белова-Недовизий, Айсылу Гарипова, Булат Гыйльванов,
Светлана Ибраһимова, Фәридә Ризаева, Фәридә Харрасова,
Илгиз Шәмсетдинов, Рушан Шәмсетдинов рәсемнәре

Инглизчәгә Ләйсән Гарәфетдинова тәрҗемәсе
Русчага Наил Ишмөхәммәтов тәрҗемәсе

Автор-составитель Галимзян Гильманов

Иллюстрации Ольги Беловой-Недовизий, Айсылу Гариповой,
Булата Гильванова, Светланы Ибрагимовой, Фариды Ризаевой,
Фариды Харрасовой, Ильгиза Шамсутдинова, Рушана Шамсутдинова

Перевод на английский Лейсан Гарафутдиновой
Перевод на русский Наиля Ишмухаметова

**Татар мифлары – балаларга = Татарская мифология для детей** / [авт.-
Т23 төз. Г. Гыйльманов]. – Казан : Татар. кит. нәшр., 2018 . – 95 б.
ISBN 978-5-298-03605-4

Миф-әкиятләрдә сөйләнелгән Өй иясе, Бичуралар, Убыр-Өрәкләр, Шүрәлеләр, Ялмавыз-Диюләр, Аждаһа-Юхалар кайда яши? Алар кешеләргә никадәр игелекле һәм никадәр дәрәҗәдә куркыныч? Әлеге китапны кулына алган һәр бала шушы сорауларга җавап табачак.

Һәрбер мифологик персонаж турында өстәмә укыр өчен әдәби әсәрләр дә тәкъдим ителә.

Где живут домовой, оборотень, призрак, Бичура, Шурале, Ялмауз, Див, Аждаха, Юха, о которых рассказывается в мифах, сказках? Насколько они добры к людям, в какой степени страшны? В данной книге каждый ребёнок найдёт ответы на эти вопросы.

Чтобы узнать о каждом мифическом персонаже поподробнее, предлагается дополнительная литература.

УДК 821.1/.8-34
ББК 84(0)-4

ISBN 978-5-298-03605-4

© Татарстан китап нәшрияты, 2018
© Гыйльманов Г. Х., авт.-төз., 2018

## МИФЛАР КАЯН БАРЛЫККА КИЛГӘН?

Борынгы кешеләр тормышны, чынбарлыкны, табигатьне мифлар аша аңларга тырышкан. Мифлар — Галәм һәм Табигать, Тереклек һәм Кешелек дөньялары белән идарә итүче, Кешенең яшәешен, аның рухиятен үз ихтыярында тотучы аллалар сыйныфы, аларның Күктәге, Җирдәге, Һавадагы, Судагы иярченнәре белән бәйле ышанулар.

Борынгырак дәверләрдә кеше һәр табигать күренешен бөек сер, тылсым итеп кабул итә һәм бу сер-тылсымнан илаһилык эзли, аны изгеләштерә, аллалаштыра. Шул рәвешле башта берәр нәрсәгә — утка, суга яисә гади генә агачка, куакка, хәтта үләнгә табына, аннары кош-җанварларны, хайваннарны илаһилаштыра башлый.

Соңрак аның рухи дөньясына табигатьтән дә аерылып бетмәгән, әмма инде кеше сыйфатларына да ия булган аллалар,ияләр, рухлар, мифик затлар килеп керә.

Бу китапта сурәтләнгән мифик персонажлар да — җир өстендәге, кешелек дөньясындагы яшәеш барышына тәэсир итәргә тырышучы түбән рухи затлар.

## ОТКУДА ПОЯВИЛИСЬ МИФЫ?

Древние люди жизнь, реальность и явления природы пытались объяснять через мифы.

В древние века человек поклонялся каждому явлению природы, воспринимая его как великую тайну, волшебство, в этом, по его мнению, проявлялась божественная сущность. Таким образом, вначале человек обожествлял огонь, воду или дерево, куст, даже траву, потом — птиц и животных.

Задумываясь о своём месте в мире природы, всё больше осознавая своё превосходство, человек начинает постепенно одушевлять и очеловечивать образы богов. Так в духовном мире человека появляются мифические существа, духи, боги, наделённые человеческими качествами и в то же время неразрывно связанные с природой.

Мифические персонажи, изображённые в данной книге, — духовно низкие существа, пытающиеся влиять на жизнь человечества на земле.

## ӨЙ ИЯСЕ

## ДОМОВОЙ



«Өй иясе» (6+) әкияте,
Р. Шәрипов: «Йорт иясе» (12+)

Сказка «Эй иясе» (6+)

Өй иясе (Йорт иясе, Йорт анасы) — кешеләргә күренмәсә дә, һәрдаим үзенең барлыгын сиздереп торган рухи зат. Ул, гадәттә, кешегә охшашрак, әмма кешеләрдән тәбәнәгрәк буйлы карт рәвешендә күзгә күренә. Бөкрерәк гәүдәле, җыерчык баскан ак чырайлы, зур күзле, җитү чал чәчле, кайчакта сакал-мыегы да бар. Ул күп очракта кеше шикелле киенгән булыр, ак киндер күлмәк-ыштаннан, бик сирәк кенә очлаебрак торган башлык кигән итеп күрәләр. Өй иясе күбрәк идән астында гомер сөрә.

Өй иясе, күпчелек очракта, өйне, бу нигездә гомер итүчеләрне яклаучы һәм саклаучы буларак кабул ителә. Ләкин моның өчен өйдә, нигездә тынычлык, иминлек булырга тиеш. Өй иясенә сабыр һәм итагатьле булган очракта, ул үз ярдәмен меңе белән кайтара. Берәр бәла-каза килсә, янгын чыкса, су басса яисә караклар керсә, Өй иясе шундук



*Рарог — чехларда өй иясе.*

*Рарог — чешский домовой.*

*Яков Коблов:*

«Ой зясе» (хозяин дома, домовой) жилищем своим обыкновенно избирает подполье, откуда и выходит по ночам. В воображении татарина он рисуется стариком, носящим довольно длинные волосы. Домовой — заботливый хозяин и, по признанию татар, даже полезная тварь. Он оберегает дом, в предчувствие беды всю ночь ходит, беспокоится и вздыхает. Если случится какое-либо несчастье ночью, например, пожар, а люди спят, он будит их, трясёт за ноги или стучит. Обыкновенные занятия домового следующие: ночью он чешет голову; иногда сеет решетом муку, это признак хороший, обещающий богатство; воет домовой не к добру — это означает приближение бедности. При хороших



*Хайнцель — немецларда өй иясе.*

*Хайнцель — немецкий домовой.*

ярдәмгә киләчәк, ул тәрәзә шакып, бер дә булмаса, аяктан яки юрганнан тарткалап уятачак...

Өй иясе белән нindирәк мөгамәләдә булырга соң? Төп кагыйдә: «Өй иясенең барлыгын тоеп, белеп яшә, иң мөһиме, аның белән тату яшә, әмма бу зат белән бернинди уртак эшең дә булмасын». Аның белән яхшы мөнәсәбәт урнаштыру өчен, сәдака биреп торырга кушканнар. Аны «якшәмбе сәдакасы» дип тә атыйлар, чөнки ул якшәмбе көнне авылның мулласына, изге картларына яисә ятимнәргә бирелә. Еш кына, Өй иясен бәхилләтер өчен, тары ярмасыннан махсус ботка пешереп, өй почмагына яисә нигез туфрагына төшереп куялар.

Өй иясе белән янәшә Абзар иясе дә яши. Себер татарлары аны «Мал иясе», «Зәнги (Сәнги) баба», «Пәша-ана» дип атыйлар.

Татарларда абзар иясе абзар-кураларга, келәтләргә, гомумән, ихата-ишегалдына хуҗа зат буларак билгеле. Абзар иясенең кешегә ярдәме зур. Мәсәлән, ул сыеры бозаулый башлаган, сарыгы бәрәнләгән кешене күршесе яисә туганы тавышы белән, соң чиктә тәрәзә шакып булса да уята, яңа туган малны туңып үлүдән саклап кала.

отношениях домовой бывает благодушным, заботливым хозяином. Полезно его иногда умилостивлять. Чтобы умилостивить домового, хозяин дома должен давать милостыню. Эта милостыня раздаётся обыкновенно в «русский» воскресный день и носит название «якшамбе садакасы».

*Каюм Насыри:*

«Абзар-ияси» (хозяин хлевов). Так называется воображаемый властелин домашнего скота, лошадей и коров. (...) Та скотина, которую он полюбит, всегда бывает жирна, гладка и красива, а которую возненавидит, та бывает потна и быстро худеет. Имеются такие чудаки из татар, которые, заметив худобу или частую опотелость на лошади, продают её и при этом выражаются так: «Эта лошадь мне не по цвету», то есть не нравится абзар-ияси.

# ӨЙ ИЯСЕНЕҢ ИЗГЕЛЕГЕ

Сырхау анасы белән генә бер кыз яшәгән. Анасы авыру булгач, ул кияүгә дә чыкмаган, дус кызлары белән дә аралашмаган.

Бервакыт урам буйлап бер имче карчык узып бара икән. Кыз аның янына йөгереп чыккан да анасын дәвалап карарга өенә чакырган. Имче карчык кызның сүзен аяк астына салмаган, авыру хатын янына кергән. Түшәктә яткан анага күз сирпеп кенә алган да әйткән:

— Анаңны терелтә алам, тик син моның бәрабәренә ике күзеңне бирерсең, — дигән.

— Бирәм, бирәм, анамны гына аякка бастыр, — дигән кыз.

Имче карчык авыру ананы имләп терелткән дә, кызның ике күзен алып, үз юлына китеп барган. Сукыр кыз анасы белән бергә матур гына яши башлаган. Күзләре күрмәсә дә, аның җаны тынычланган — газиз анасы терелеп аякка басты бит! Егылып, бәрелеп, бөтен тәне күгәреп бетсә дә, ул эченнән генә сөенеп, куанып туя алмаган.

# БЛАГОЧЕСТИЕ ДОМОВОГО

В одном ауле жила девушка, и никого у неё не было, кроме больной матери. Она и замуж не вышла из-за болезни матери, и с подругами не общалась.

Однажды по улице шла старая знахарка. Девушка увидела её, подбежала и пригласила в дом, чтобы та вылечила её маму. Знахарка не отказала девушке, подошла к постели больной. Кинув беглый взгляд на мать, сказала:

— Я вылечу твою маму, но ты за это отдашь мне зрение.

— Отдам, отдам, только маму на ноги поставьте, — ответила дочка.

Знахарка вылечила больную мать заговорами, забрала зрение у девушки и пошла своей дорогой. Слепая дочка и выздоровевшая мать зажили с той поры радостно, не ведая печали. Хоть и ослепла девушка, но душа её спокойна — ведь любимая мама выздоровела, она не прикована к постели!



Менә хикмәт: сукыр кыз торган өй идәне астында үз гаиләсе белән Өй иясе яшәгән, имеш. Кыз берәр нәрсәгә абынып егылган саен, астагы ияләр дөньясы дер селкенеп ала икән. Ияләр тормышында тынычлык беткән. Өстәге дөбердәгән тавыштан алар нишләргә дә белмәгәннәр.

Өлкән Өй иясе иң акыллы, иң зирәк якыннарын үз тирәсенә җыеп киңәшә башлаган. Ниһаять, бер карарга килеп, рухлар үз почмакларына таралышканнар. Ә Өй иясе үзе сукыр кыз янына менеп киткән.

Кыз бу вакытта җеп эрләп утыра икән. Үзе моңлы итеп җырлый, ди:

Күңелемне ачып бирим әле,
Күңелемдә минем моңнар бар.
Бу җырымны бөтен дөнья тыңлар,
Бу җырымны җилләр тыңларлар...

Шулвакыт кызның колагына ят бер тавыш ишетелеп калган:
— Бу җырыңны ияләр тыңлар...

И пусть всё тело девушки покрыто синяками от постоянных падений и столкновений с косяками и мебелью, сердце её переполнено радостью.

Однако под полом того дома, говорят, жила семья домового. Каждое падение слепой девушки вызывало переполох по ту сторону пола. Спокойная жизнь семьи домового закончилась. Дух дома не знал, как избавить себя и семью от этого грохота.

Собрав самых мудрых, старейшина домовой стал держать совет. Наконец, придя к общему мнению, духи разошлись по своим углам. А старейшина домовой отправился напрямки к слепой девушке.

Она в это время сидела за прялкой и напевала:

Расскажу-ка, что у меня на душе,
Душа моя грустью дышит.
Мою песню услышит весь мир,
Мою песню ветер услышит...

В эту секунду до девушки донёсся посторонний голос:
— Эту песню домовые услышат...



Кыз, сискәнеп, сикереп үк торган:

— Кем бар монда, кем бу? — дип өзгәләнгән ул.

Беркем дәшмәгән.

— Әнием, син шаяртасыңмы әллә?

Бу юлы да беркем тавыш бирмәгән. Бераздан, йомшак җил сулышы бәрелгән кебек кенә, кызның колагына пышылдау тавышы ишетелгән: «Капканы чыгып уң якка борылсаң, авыл читендәге күперне узып үргә күтәрелсәң, ике тау куенында саркып яткан билгесез чишмәгә юлыгырсың... Шуның суы белән күзләреңне ю... Юганда, моңлы җырыңны җырла. Тик аны «Күзләремне ачып бирим әле...» дип башла,

Девушка вздрогнула от неожиданности и даже вскочила со стула:

— Кто здесь, кто это? — встревожилась она.

Никто ей не ответил.

— Мама, это ты шутишь со мной?

И в этот раз никто ей не ответил. Через некоторое время до девушки долетел едва слышный шёпот, похожий на дуновение ветерка: «Если выйдешь из ворот и, повернув направо, дойдёшь до околицы села, выйдешь через мостки, затем поднимешься в гору и вскоре обнаружишь безымянный ручей, текущий в лощине между двух гор... Вымой глаза водой из этого ручья, а сама напевай протяжную грустную песню. Главное,

«Бу җырымны ияләр тыңлар» дип бетер... Барысын да шунда аңларсың...»

Кыз баштарак куркып, шикләнеп калган. Әмма аның бик тә күзле, якты дөньялы буласы килгән. Ул нәкъ Өй иясе әйткәнчә эшләгән: капшана-капшана капкадан чыгып, уң якка киткән, сак кына басып, авыл читендәге күперне узган, үрмәләп менеп, тау куенындагы билгесез чишмәне барып тапкан... Аннары, тезләнеп, кушучлап су чумырып алган да битенә, күзләренә сирпегән... Үзе моңлы итеп җырлаган:

Күзләремне ачып бирим әле,
Күзләремдә минем моңнар бар.
Бу җырымны бөтен дөнья тыңлар,
Бу җырымны ияләр тыңлар...

Шулвакыт аның күз алдында кабат якты дөнья ачылып киткән. Кыз тагын күрә башлаган. Аның моңлы дөньясына тагын шатлык, дәрт, өмет кереп тулган.

начни её словами «Открою-ка я глаза...», а заверши так: «Эту песню домовые услышат...» Ты сама поймёшь, для чего это...»

Девушка поначалу испугалась, засомневалась. Но ей очень хотелось стать зрячей, вновь любоваться красотами мира. Она сделала всё так, как посоветовал домовой: на ощупь вышла за ворота, свернула направо, осторожной поступью вышла через мост на краю села, поднялась в гору и нашла безымянный родник... Затем, сев на колени, набрала полную пригоршню воды и брызнула на лицо, на глаза... Тихонько запела:

Открою-ка я глаза,
Глаза мои грустью дышат.
Эту песню услышит весь мир,
Эту песню домовые услышат...

В тот же миг пред ней раскрылся во всех красках белый свет. Девушка прозрела. Её печаль сменилась радостью, она обрела силы и надежду.

# БИЧУРА



М. Гыйлаҗев: «Бичура» (12+)

М. Гилязов: «Бичура» (12+)

Бичура — бер ярым-ике аршин (ике терсәк) буйлы, билсез гәүдәле зат, башында өрпәк — борынгы татар хатын-кызлары кия торган башлык. Өстендә — кызгылт күлмәк. Йөзе сискәнерлек дәрәҗәдә карт, җыерчыклы, корымга, тузанга буялып беткән, чал чәчләре башлык читеннән күренеп, тырпаеп тора. Күзләре чем-кара — эчкә баткан төртке (кайчакта — күмер кебек янып торган) күзләр, иякләре очлаеп алга чыккан, тешләре сирәк...

Бичураның иң киң таралган яшәү урыны — өй, караңгы почмак, махсус бүленгән кара бүлмә; ул бигрәк тә почмакка сөяп куелган себеркене ярата, еш кына шул себерке артында, яки аның белән бергә кара якта яисә чоланда яши... Себеркегә атланып йөрергә ярата.

Өй иясеннән аермалы буларак, чисталык яратмый, яшәү өчен шактый пычранган, шакшыланган,



*Барабао — итальян бичурасы.*

*Барабао — итальянский бичура.*

*Яков Коблов:*

Бичура — это баснословное существо, то же, что у русских кикимора или «соседка». Бичура представляется татарину в виде женщины ростом от полутора до двух аршин; на голову у неё надет «ирпак» (старинный женский татарский головной убор). Бичура живёт в жилых помещениях — на подволоке (чердак), в подполье и в банях, но не у всех, а только у некоторых хозяев. Некоторые отводят для неё особую комнату, где её поят и кормят. На ночь оставляется тарелка с пищей и несколько ложек. Наутро в тарелке Бичура ничего не оставляет, всё съедает. А если рассердится за что-нибудь на хозяина, то разбивает чашку, в которой ей подаётся пища, и раскидывает всё, что попадёт ей под руку.



*Аканамэ — японнарда пычракта яши торган зат.*

*Аканамэ — японское мифическое существо, живущее в грязи.*

керләнгән өйләрне сайлый. Аның башына кигән өрпәге шулкадәр керләнеп, корымга, аш-су маена катып беткән, ди, аның һәр очы кулбашыннан әле алга, әле артка салынып йөри, имеш. Суны идән астына түксәң яисә мич астында, мич артында чүп-чар оясы булса, Бичураның шул пычраклыкка ияләшүен көт тә тор.

Татар Бичурасы иң элек кешегә, йортка ияләшә. Ул кешеләрдән әллә ни куркып, тартынып тормый, хәтта кешенең йоклаганын да көтмичә, үзе яшәгән өйгә кайтып керә. Ул — төн рухы, шуңа күрә аны бернинди ишек тә, бик тә тотып кала алмый... Өй эчендә ул аеруча тынгысыз: төнге сәгатьләрдә кинәт кенә идән себерә башлый яки табак-савытларны кузгатып йөри. Яраткан шөгыле — йоклап яткан хуҗаларны куркытып, мич башыннан сикереп төшү...

Бичура ияләшкән икән, аннан ничек котылганнар соң? Яңа йортның бурасын яңадан сүтеп җыйганнар. Өйгән чакта ук, яңа салынган мичнең морҗасыннан төтен чыгарганнар. Бичураны ир-атлар — утлы кисәүләр, пумалалар күтәреп, хатын-кызлар — табагачларга атланып, үкереп, кешнәп, чүмечләр, табалар, чиләкләр кагып, куып җибәрергә тырышканнар.

Бичура нередко во сне давит человека, любит внезапно пугать его и вообще озорничает над людьми. Вдруг, откуда ни возьмись, пролетит кирпич, полено...

*Каюм Насыри:*

Она не причиняет никакого существенного вреда татарину, но сильно и на разные лады беспокоит его ночью: кричит, играет, смеётся, шутит, спящего перетаскивает с места на место; вещи, положенные в одно место, прячет в другое. У татар о ней имеется поговорка: «Куда делась эта вещь; не бичура ли украла?» Если закроют трубу, ночью она откроет, и вообще шалит. Как попадает в дом бичура? Татары об этом говорят вот что: она попадает в дом тогда, когда татарин долго не кладет в нём печи, а потом переходит в него на житьё. Есть ли средства выгнать из дома бичуру? Одни говорят, что для этого нужно разобрать весь дом и построить его на другом месте, а другие утверждают, что довольно привести в дом медведя, и бичура убежит.

# ЯШЬ КИЛЕН БИЧУРАНЫ ҖИҢӘ

Бер Бичура йорт хуҗасы белән һич тыныша алмаган. Бу яшь ир-егет дөнья көтәр өчен хатынлыкка нинди генә чибәр һәм уңган кыз алып кайтса да, яшәргә ирек бирмичә, үз шуклыклары белән интектереп, бу киленне китәргә мәҗбүр итә, ди. Бичураның шуклыкларына бер хатын-кыз да түзә алмый икән. Ул әле аларның кием-салымын, яулыкларын яшерә, әле таралган чәч толымнарын тузгытып-сүтеп китә, әле юылган табак-савытларын пычрата, ватып бетерә, йокларга яткач, куркытып, буып җәфалый...

Бервакыт килен булып бу йортка тагын бер кыз төшкән. Бичурага шул гына кирәк тә: аны шундук эзәрлекли дә башлаган. Әмма килен дә акыллы булган. Бичураның холкын ул бик тиз аңлап алган. Беркөнне иренә: «Өч көн кайтмый тор, мин Бичура белән нәрсә эшләргә кирәген белермен», — дигән. Аның хәйләсе бик гади икән. Бичура нәрсә эшли — ул да шуны эшли башлаган. Бичура мич башына менеп сикерсә, ул да мич башына менеп, сикереп төшә, Бичура табак-савыт шылтыратса, ул да шылтыратып куя... Бичурадан күрмәк, мичнең көлен алып, бөтен идәнгә, ишек тупсаларына, тәрәзә төпләренә сибә, гөлләрнең туфрагын тузгыта...

# КАК МОЛОДАЯ НЕВЕСТА БИЧУРУ ОДОЛЕЛА

Одна Бичура никак не могла ужиться с хозяином. Какую бы пригожую, приветливую, на все руки мастерицу-невесту хозяин в дом ни привёл, Бичура не давала молодым житья, лишала их покоя своими проделками, вынуждая очередную невесту вернуться к родителям. Ни одна из них не смогла выдержать столь беспокойную соседку. То она их одежду, платки спрячет, то спутает только что расчёсанные пряди, измарает свежевымытую посуду, разобьёт её, а по ночам не даёт спать, пугает, хватает за горло, пытается душить...

Однажды в этот дом пришла очередная невеста. А Бичуре только этого и надо: в тот же день она стала её изводить. Но невеста была девушкой смышлёной. Она быстро разгадала характер Бичуры. В один из дней она сказала мужу: «Три дня не возвращайся домой, а я за это время попытаюсь одолеть Бичуру». Секрет её весьма прост. Что Бичура вытворяет, то же самое и она повторяет. Бичура взбирается на печку и спрыгивает на пол,



Шулай бер көн үтә, ике көн... Бичура тәмам аптырый: каршы торучы булмагач, болай яшәүнең бер кызыгы да юк икән.

Килен, берни булмагандай, ћаман икенче Бичура булып кылана, чын Бичурага үз этлекләрен кылырга ирек бирми.

Өченче таң атканда, хәлсезләнгән, арыган-талчыккан Бичура өйне ташлап китә.



и она следом за ней залезает на печь и прыгает, Бичура гремит посудой, и она гремит тарелками да тазами... Подсмотрев у Бичуры, набрала золу из печи и рассыпала по всему полу, на ступеньки крыльца и на подоконники, вытряхнула и развеяла повсюду землю из цветочных горшков...

В таких забавах один день прошёл, второй... Бичура в недоумении: если никто не противостоит тебе, не ругает, то от проказ никакого интереса нет, оказывается.

А невестка, как ни в чём не бывало, продолжает исполнять роль второй Бичуры, не давая возможности творить безобразия настоящей. На рассвете третьего дня, измождённая и потрёпанная, она покинула дом.

# СУ БАБАСЫ. СУ ИЯСЕ. СУ АНАСЫ
# ВОДЯНОЙ ДЕД. ВОДЯНОЙ ХОЗЯИН. ВОДЯНАЯ

Г. Тукай: «Су анасы» (0+), «Өч ул» (0+), «Беләк буе кайрак» әкиятләре



Г. Тукай: «Водяная» (0+), сказка «Дух воды» (0+)

Легенда-риваятьләрдә сулыклар иясе берничә мифик персонаж аша тасвирлана: Су бабасы, Су иясе, Су анасы (Су кызы).

Су бабасы күлләрнең, сазлыкларның иң ерак почмакларында яши. Яшькелт йөзле, кызгылт күзле, чәчләре урынына — суүсемнәр, тәнендә балык тәңкәләренә охшашлы, кабырчыклы «киеме» булган бу затның кул-аяклары хакында хәбәрләр юк, ул судан чыкмый, үзен борчыганны өнәми. Сулыкның иң ерак, иң тирән урыннарына кергән кешеләрне, ачуы чыгып, үз янына — су астына да тартып алырга мөмкин. Сулыкларны пычраткан кешеләргә һәм яр буендагы шау-шулы яисә һәр җирдә тегермән төзеп, аның тынычлыгын алган авылларга карата Су бабасы чын-чынлап рәхимсез дә була ала. Мәсәлән, ул тыныч, аяз, җилсез көндә елга-күлләрдә, буаларда давыл куптара алган,



*Вумурт — удмуртлар-да су иясе.*
*Вумурт — дух воды у удмуртов.*

*Яков Коблов:*

В водных пространствах есть свои властители и обитатели, которые иногда в человеческом виде являются людям. Существа эти следующие: «Сыу бабасы» (водяной дед), «Сыу эясе» (водяной хозяин), «Сыу анасы» (водяная мать). Из этих трёх существ составляются в водных пространствах семейства. Народные легенды и рассказы не выясняют достаточно, как нужно представлять взаимоотношение этих существ между собою. По одним рассказам можно думать, что «Сыу бабасы» — главный хозяин водных пространств, «Сыу анасы» — его жена, «Сыу эясе» — его сын, находящийся у него в полном подчинении. На основании других рассказов можно предполагать,



*Анкы келе — чукчаларда диңгез иясе.*
*Анкы келе — дух-хозяин моря у чукчей.*

дулкыннарын күккә чөйгән, буаларны ерып җибәргән, су тегермәннәренә зыян салган, кешеләргә хәтәр чир-авырулар («су авыруы») җибәргән.

Су иясе чибәр егет образында күзаллана. Кеше йөзле, озын җирән яисә кара чәчле, бүлтәеп калкып торган йомры күзле бу зат сөйләк-риваятьләрдә барыбер дә әле ярымкеше, ярымбалык кыяфәтендәрәк сурәтләнә. Ул аеруча сулыкларның корып юкка чыгуыннан курка.

Су анасы үзенең кыяфәте белән дә, холкы-тәртибе белән дә кешегә охшаган: зифа гәүдәле, җиргә тиеп торган озын, куе чәчле, зур һәм озынча башлы җан иясе. Күзләре кара, зур, тышка калкып чыгып тора. Русларның Русалкасыннан аермалы буларак, аның койрыгы юк, булса да, бик зәгыйфь, ул авылга үз аягы белән килеп йөри...

«Су атасы» дигән мифик персонаж да очрый. Ул күбрәк кыш көннәрендә күренә. Аулак елга буйларында, ерак күлләрдә бәке тишеп, шул бәке читендә бозга туңган ак (кайчакта җирән) сакалын тарап утырган бер кәрлә картны күрсәгез, Су атасы әнә шул инде. Ул усал да була ала. Кыш көннәрендә елга-күл өстендә каткан бозга суккалап, типкәләп йөрсәң, Су атасы, син басып торган урындагы бозны ватып, аска тартып алырга мөмкин.

что «Сыу бабасы» — уже отживающий свой век старик, хотя ещё крепко держащий власть в своих руках, но уже значительную долю её уступивший своему сыну, имеющему жену — «Сыу анасы».

*Каюм Насыри:*

«Су-анасы», как показывают сами слова, есть существо женского пола, ибо по-русски означает «водяную мать». Так как у татар нет более имён водяным существам, исключая юхи, не родственной по своему происхождению описанным сейчас, и так как, по словам татар, сказанные существа родственны между собою, то я заключаю, что «су-анасы» есть мать «су-ияси» и жена «су-бабасы». Ещё надобно заметить, что «су-анасы» бывает иногда видима нечаянно подошедшему к воде татарину в образе женщины, чешущей себе гребнем волосы.

## СУ АНАСЫ БЕЛӘН ЯЛМАВЫЗ

Моннан бик ерак та булмаган, бик якын да булмаган бер авыл янында матур күл җәелеп яткан. Бу күлдә Су анасы гомер кичергән. Аның җаны алтын тарагында икән. Тараксыз калган Су анасын үлем көткән. Ә Су анасы үлсә, сулыклар — күлләр, елгалар кибә, юкка чыга, су китсә, кешеләр тормышына да афәт килә, имеш.

Бервакыт бу авылга олы бәла килгән. Якындагы тауларда Каф тавыннан Җиде диңгез артына кайтып баручы, үзе дә тау кадәрле Ялмавыз хәшәрәт тукталган. Менә шул хәшәрәт зат авылга каныккан да инде.

— Бер тәүлек эчендә минем сыңар күзем авырлыгы кадәр асылташ, алтын-көмеш җыеп китермәсәгез, авылыгызны ялап алачакмын! — дигән ул.

Авыл халкы кара кайгыга баткан. Кемдә күпме асылташ, алтын-көмеш бар — авыл уртасына өя башлаганнар. Кечкенә генә алтын тавы барлыкка килгән. Кемдер нәсел әбиләреннән күчеп килгән алка-беләзекләрен, балдакларын алып килгән, кемдер бил каешының көмеш аелын салдырып биргән, кемдер кылыч-хәнҗәр кынындагы асылташларны чокып алган...

## ВОДЯНАЯ И НЕНАСЫТНОЕ ЧУДОВИЩЕ ЯЛМАУЗ

Ни далеко, ни близко отсюда рядом с одним аулом было красивое озеро. В нём жила Водяная — Су анасы.

Её душа была спрятана в золотом гребне. Оставшаяся без гребня Водяная обречена на скорую смерть. А если умрёт Су анасы, то пересохнут все реки, озёра, ручьи и ручейки, а без воды не выживут и люди.

Однажды в эту деревню пришла большая беда. На ближайших горах устроилось отдохнуть возвращавшееся из-за тридевять земель, из-за семи морей ненасытное чудовище — огромный и безобразный Ялмауз. Вот это чудище-то и присосалось к деревне.

— В общем так, если вы не принесёте в течение суток столько драгоценных камней, золотых и серебряных украшений, сколько весит мой единственный глаз, то я сотру ваш аул с лица земли, языком слизну, — пригрозил Ялмауз. Оказывается, эта мерзкая гадина питается бриллиантами, золотом и серебром.



Бер тәүлек вакыт үтүгә, мәйдан уртасында Ялмавыз пәйда булган. Гайрәтне чигерерлек килбәтсез, капка кадәр зур авызлы, шул авызыннан асылынып торган озын кызыл телле, тәрәзә кадәр сыңар күзле, кылган кебек тузган чәчле, әрекмән яфрагы җилбәгәй колаклы бу хәшәрәт затка карап, кешеләрнең исләре-акыллары китеп торган. Ялмавыз шулкадәр килбәтсез гәүдәле булган ки, ул, үз гәүдәсе белән авылны кояштан каплап, караңгы көн тудырган. Шомлы ай кебек, аның сыңар күзе генә ялтырап тора икән...

Бераздан аңнарына килеп, кешеләр мәйдан уртасына зур бизмән ясаганнар. Бу бизмәннең урта багана очы болытларга кадәр тиеп торган, дип тә сөйлиләр. Үлчәүнең бер як тәлинкәсенә авыл халкы үзләре җыйган алтын-көмешләрне, асылташларны тутыра башлаган. Ялмавыз исә үзенең шардай күзен чокып алып, икенче яктагы тәлинкәгә китереп салган. (Әйе-әйе, явыз рухларның күзләре алынып, кире куела торган була икән!) Менә галәмәт: күпме генә алтын-көмеш, асылташ салсалар да, Ялмавызның сыңар күзен басып китәрлек җыя алмыйлар, ди...

Жители села погрузились в беспросветную печаль. На середину села каждый принёс все драгоценности, золотые и серебряные украшения, какие у него были. Получилась небольшая кучка. Кто-то принёс доставшиеся по наследству от бабушки серьги, браслеты, кольца-перстни, кто-то отцепил от ремня серебряную пряжку и положил в общую кучу, кто-то выковырял драгоценные камни из ножен кинжала...

Через сутки на сельской площади появился Ялмауз: безобразный, огромный, словно ворота, рот, из которого свисает длинный красный язык, размером с окно единственный глаз посреди лба, спутанная, седая, похожая на ковыль шерсть, уши большие, как лист зрелого лопуха. Глядя на такое уродство, всё село онемело от страха, не в силах что-нибудь вымолвить. Ялмауз был настолько огромным, что заслонил своим телом солнце и погрузил аул во тьму среди бела дня. На небе зловеще сверкал лишь единственный глаз Ялмауза...

Вскоре, придя в себя, люди организовали на площади большие весы-безмен. Рассказывают, мол, опора этого безмена доставала до облаков. На одну чашу безмена сельчане начали складывать золотые и се-



Менә шунда мәйдан уртасында гаҗәеп хәл булган. Авыл читендәге күлдән, ай нурлары төсле балкып, елкылдап торган озын чәчләреннән су агыза-агыза, Су анасы килеп чыккан да, чәченнән алтын тарагын алып, алтын-көмешләр өелгән тәлинкәгә китереп салган. Салган да, тирәягына бер багып та карамыйча, кабат үз күленә кереп киткән... Шул мәлдә бизмән тәлинкәләрендәге авырлык тигезләшкән...

Ялмавыз, шардай күзен кабат урынына куеп, барлык алтын-көмешне алып, үз юлына китеп барган. Авыл исән-сау торып калган.

ребряные украшения, драгоценные камни. А Ялмауз выковырял свой шаровидный глаз и бросил на вторую чашу весов. (Да-да, глаза у нечистой силы можно вынуть из глазниц, а потом вернуть на место!) Но вот ведь какая незадача: сколько бы драгоценных камней, золота и серебра ни клали сельчане, перевесить единственный глаз Ялмауза не получалось.

И вот тогда-то на сельской площади произошло невиданное событие. Из озера, что находится вблизи аула, вышла Водяная, с длинных прядей её стекала, лучась и сверкая, вода. Су анасы вынула из волос золотой гребень и положила на чашу с драгоценностями. Положила и, не взглянув ни на кого, снова вернулась в своё озеро... Ровно в эту минуту чаши уравновесились...

Тик... үз тарагын биргән көннән алып, Су анасы яр буенда бүтән күренмәгән... Су анасы тараксыз калган. Җансыз калган. Үз җаны сакланган таракны Ялмавыз хәшәрәткә корбан иткән Су анасы, кешеләр аңа дан җырлап, шатланып йөргән вакытта, күл төбендә соңгы сулышын алып яткан.

Игелекле Су анасының һәлакәтен изге Тәңребез тыныч кына карап тора алмаган, әлбәттә. Ул үзенең өлкән улы Кояштан Су анасы өчен яңа тарак ясавын сораган. Кояш озак ялындырмаган — үз нурларыннан коеп, Су анасына матур тарак бүләк иткән. Шулай итеп, Су анасына кабат җан иңгән. Сулыкларга кабат — сафлык, авыл тормышына ямь кергән.

Тәңре Ялмавызны да буш калдырмаган. Ул хәшәрәт туклана торган алтын-көмешне үләксә өеменә әверелдергән. Ялмавызның эче күбеп, көннәрдән бер көнне ул бөтен дөньяны сасытып шартлаган, ди, дөрес булса...

Ялмауз, водрузив единственный глаз на место, сгрёб все драгоценности и пошёл своей дорогой. Аул не пострадал.

Однако... с того дня Водяная больше не появлялась на берегу озера... Су анасы осталась без гребня. Без души. Водяная, отдавшая ненасытному Ялмаузу золотой гребень, в котором хранилась её душа, лежала при смерти на дне озера в то время, как благодарный народ пел здравицы в её честь, радовался и веселился.

Конечно же, Великий Тенгри не смог равнодушно смотреть на умирающую Су анасы. Он попросил своего старшего сына Солнце изготовить для Водяной новый гребень. Солнце не заставил долго себя уговаривать — из своих лучей отлил новый гребень и подарил его Водяной. Су анасы снова ожила. Водоёмы очистились и засверкали, жизнь села заиграла новыми красками.

Не обделил вниманием Тенгри и Ялмауза. Все драгоценности, которые проглотил ненасытный обжора, он обратил в падаль. Брюхо Ялмауза раздуло, говорят, в один из дней, обдав всё вокруг нестерпимой вонью, оно лопнуло, если не обманывают, конечно...

# АЛБАСТЫ



Г. Гыйльманов: «Албастылар» (12+)

Кеше яшәми торган йортларда, ташландык җирләрдә, кырларда, чокыр буйларында яшәүче кара көчләргә, явыз рухларга «Албасты» дип исем биргәннәр. Каюм Насыйри аның кеше кыяфәтендә генә йөрүе хакында язса, Яков Коблов, киресенчә, аның зур ат йөге, кибән, эскерт, хәтта чыршы рәвешендә булуын хәбәр итә. Бу ике фикер дә халыктан язып алынган чыганаклар белән дәлилләнә. Димәк, икесендә дә хаклык бар. Шундый нәтиҗәгә килергә мөмкин: Албасты, түбәнге рух, шаукымлы, ягъни сихер белән бәйле зат буларак, бер халәттән икенчесенә күчәргә сәләтле.

Татар мифларындагы Албасты кешеләрне басып, буып газаплый. Ерак чакрымнар буе бер агач, бер таш, бер су, бер торак, авыл булмаган ялан кырда («Албасты каргаган җир») күкрәк читлекләре ватылган кеше гәүдәсе табып алсалар, моны, һичшиксез, Албасты явызлыгына сылтаганнар.

*Шидаркалар — әрмән мифологиясендә явыз рухлар.*

*Шидарки — злобные духи в армянской мифологии.*



*Яков Коблов:*

Именем Албасты у татар называется нечистая сила или злое существо, живущее и являющееся людям преимущественно в нежилых домах, в пустырях, на полях и в логах. Много рассказов об этой злой силе, как у татар магометан, так и у крещёных, но рассказы эти чрезвычайно однообразны. Является людям Албасты в виде человека, а больше всего в виде большого воза, копны, стога, скирда, ёлки и т. д.

Опасность от Албасты заключается в том, что он может задавить человека насмерть, причём ещё пьёт иногда у него кровь. Когда Албасты давит человека, то последний чувствует сильное сердцебиение и удушье.





*Албыс — тыва, алтай албастысы.*

*Албыс — тувинский и алтайский албасты.*



*Эль песадиэйю — испан албастысы.*

*Эль песадиэйю — испанский албасты.*

Борынгылар матча астында йокларга кушмаганнар. Матча — җен-пәриләр, Албасты кебек явыз рухлар биләмәсе. Кеше матча астына ятса, төнлә аның өстенә матча авырлыгындагы йөк басыла дип уйлаганнар. Күкрәк читлекләре изелеп-ватылып бетәргә дә мөмкин. Шуңа да, түшәгең матча астына туры килгәндә, күкрәгеңдә авырлык сизә башлау белән, берәр догалык китабын тиз генә түшеңә салырга кирәк. Матча, түшәм такталары һәм Албасты темасына табышмак та бар: «Албасты аркылы яткан, балалары үзен баскан».

Хатын-кыз кыяфәтендәге Албастыны төрлечә сурәтлиләр. Кичләрен ташландык урыннарда кызгылт тәнле яисә киемле, тузган чәчле, шардай күзле, очлы борынлы, килбәтсез гәүдәле карчыкка тап булсагыз, һич ялгышмассыз, Албасты шул үзе була инде. Аны башка карчык-корчыклардан ничек аерырга соң? Моның өчен аның арка ягына чыгарга кирәк. Албастының аркасында тән тиресе юк, эчке әгъзалары күренеп тора, имеш.

Албасты — төнге рух. Ул төнлә генә куркыныч. Иртәнге әтәчләр аваз салу белән, алар юкка чыга, үз дөньяларына кереп бикләнәләр.

Албастыны үз ихтыярыңа буйсындырырга мөмкинме? Мөмкин, диләр. Моның өчен аның алтын бөртек чәчен кулга төшерергә кирәк. Шул гына. Ул син кушканны бик теләп үти башлаячак. Ләкин хәзергә кадәр кулга төшерелгән Албасты хакында бер хәбәр дә ишетелгәне юк.

Себер татарлары мифологиясендә Албасты бераз үзгәрәк. Ул анда авырулар рухы буларак мәгълүм. Кешеләргә озын, тарау чәчле, тезгә җиткән, асылынып торган күкрәкле, каты, үткен тырнаклы хатын-кыз кыяфәтендә күренә.

# КАЗАН ЮЛЫНДА АЛБАСТЫ

Бер кеше кыш көне җигүле атта Казаннан авылына кайтып бара икән. Үз авылына ике-өч чакрым ара калгач, ат каршында ике печән кибәне пәйда була! Җитмәсә, кичке эңгердә алар янында ниндидер утлар җемелдәп ала... Юлчы ныклабрак караса — күрә: алда печән кибәннәре түгел, чын Албасты үзе икән. Күпмедер вакыт куркуыннан торараштай катып торганнан соң, кинәт айнып китеп, ул атын куарга керешә. Үзе куа, үзе һаман-һаман артына борылып карый. Ни хикмәт: теге «ут күзле» печән кибәннәре, ягъни Албасты һаман шул урында тора. Бу кеше шунда гына аңлап ала: Албасты аны куып килә икән! Шулай куыша-куыша, алар бер чит-ят урман янына җитәләр. Каян килгәндер ул — мондый урманнарның якын-тирәдә булганы да юк икән. Иң шомлысы да шул: урман эчендә төрле көйләр, кыңгырау-барабан тавышлары яңгырый, тоныкк кына кешеләр сөйләшкәне ишетелә. Ара-тирә ат кешнәгән, сыер мөгрәгән авазлар колакка килеп ирешә...

# СБИВАЮЩИЙ С ПУТИ АЛБАСТЫ

Один человек возвращался зимой из Казани в свой аул... До деревни оставалось всего-то два-три километра, как напротив возникли два стога сена! Мало того, в сумерках рядом со стогами мерцали какие-то огни... Путник, пристально всмотревшись, понял: перед ним не два стога, а самый настоящий Албасты. Очнувшись от охватившего его оцепенения, он принялся что есть сил погонять коня. Сам погоняет, сам время от времени оборачивается. Удивительное дело: те два «глазастых стога», то есть Албасты, на том же расстоянии. Лишь тогда этот человек догадался: Албасты преследует его! Гоняясь друг за другом, они оказываются на краю совершенно незнакомого леса. Откуда взялись эти заросли? Ничего подобного здесь отродясь не было. Самое пугающее и подозрительное: в лесу раздаются различные мелодии, звоны колокольчиков, барабанный бой, негромкий разговор людей. Время от времени до ушей доносится конское ржание, мычание коров...



Бөтен белгән догаларын укый-укый, юлчы атын куыуында була. Борылып карый — теге кибәннәр һаман шунда торалар, алар арасында ут тагын да ныграк җемелди. Бу кеше, исән калудан тәмам өметен өзеп, куллары белән йөзен каплап, чана төбенә ята да: «Нәрсә булса, шул булыр! » — дип, атын үз иркенә җибәрә.

Шул мәлдә юлчының колагына әтәч кычкырган тавыш ишетелеп кала. Башын күтәреп караса, ни күрсен — төне буе артыннан куып килгән кибәннәр дә, алар янындагы ут та юк... Ат та, кинәт җиңеллек тоеп, кызурак чаптырып китә. Ул юл буйлап беренче очраган авылга барып керә. Теге кеше шакката: бу авыл аша ул кичә көндез үк үткән икән!

Соңгы көчен җыеп, ниһаять, туган авылына кайтып җитә бу. Көн яктыра. Юлда үзенең төнге эзләрен карап бара. Бара-бара да тагын бер гаҗәпләнеп куя: ник бер печән кибәне, ник бер урман-агачлык булсын, ди!

Шунда гына ул үзенең Албастыга эләгә язып калуын аңлый.

Читая все известные молитвы, путник не перестаёт погонять коня. Оборачивается: те два стога не отстают, огни между ними ещё ярче разгорелись. Распрощавшись с надеждой благополучно доехать до дома, он закрыл лицо руками и лёг на дно саней: «Чему быть, того не миновать!» — сказал и доверился коню, пусть вывезет куда-нибудь.

В эту минуту до ушей путника доносится крик петуха. Он поднимает голову и что же видит: ни гнавшихся за ним всю ночь стогов, ни устрашающих огней не осталось... И конь, почуяв некоторую лёгкость, припустил рысцой. Вскоре он вбегает в первую возникшую на пути деревню. Путник приходит в недоумение: как же так, он ведь уже проезжал через этот аул ещё вчера днём!

Собравшись с последними силами, он достиг наконец родного аула. Светало. На обратном пути человек с удивлением осматривал вчерашнюю ночную дорогу: хоть бы один стог, хоть бы один лесок?! Только тогда он понял, что чудом не попал в лапы Албасты.

# УБЫР

## УБЫР (ОБОРОТЕНЬ)

«Токый чокыры» (6+),
«Батыр солдат» әкиятләре (0+)



Ш. Идиятуллин: «Убыр» (16+)

Убыр — төрки халыклар мифологиясендә еш очрый. Татардагы «Убыр» атамасы русларның «Упырь», Көнбатыш халыкларының «Вампир» сүзләренә дә йогынты ясаган.

Убыр татар халык мифологиясендә ике төрле сурәтләнә. Бер төрлесе аерым зат, ия, явыз рух сыйфатында үзалдына, мөстәкыйль рәвештә гомер сөрә. Кеше рәвешендә күренгән бу Убырның кыяфәте аеруча куркыныч: башы утлы туп кебек түгәрәк, күзләре урынында да — утлы күмер, койрыгы нечкә, озын, яшелле-күкле-зәңгәрле утлы-ялкынлы төтен булып сузылган... Кичен яки төннәрен ул еш кына җиргә тияр-тимәс ут йомгагы булып тәгәрәп йөри, йә тубал кадәр ут булып, бер урында тирбәлеп тора. Убырның утка нисбәттә каралуы очраклы түгел. Ут ничек бар нәрсәне яндырып,



*Бака — гаитиларда скелетсыман убыр.*

*Бака — скелетообразный дух-вампир у гаитян.*

*Яков Коблов:*

Убыр — это, по поверью татар, злое кровожадное существо, живущее нераздельно и в связи с человеком, даже как будто в самом человеке. Люди, имеющие при себе Убыра, встречаются большей частью среди женщин и носят название «убырлы кеше» (человек с Убыром). Таких людей можно узнать по тому, что на головной маковке у них бывает углубление, и о таких людях говорят: «башы тишек, бу убырлы икян» (так как у него на голове ямочка — он с Убыром, носит в себе Убыра). При жизни «убырлы кеше» Убыр нередко оставляет во время сна того человека, с которым связан. Как только человек, имеющий Убыра, заснёт, Убыр выходит через печную трубу в виде огненного шара.



*Ламия — антик мифологиядә корбанының канын суыра торган ярымкеше-ярымъелан.*

*Ламия — полудеваполузмея в античной мифологии, сосущая кровь своих жертв.*

төбе-тамыры белән ашап барса, Убыр да нәфесе туймас бер комсызлык белән барын да умырып ашый, йота. Үлек-черек, үләксә — аның яраткан азыгы.

Зат-ия кыяфәтендә йөргән Убыр-утны тоту яисә юк итү — мөмкин булмаган хәлләрнең берсе. Чөнки ул теләсә кайчан теләсә нинди башка бер кыяфәткә керә ала: теләсә — эткә, мәчегә, теләсә, матур кызга әверелә... Ә теләсә... кеше аяклы, кеше куллы, дуңгыз йөзле, дүрт аяклап йөри торган җанварга әверелеп, кеше котын ала.

Убырларның икенче бер төрлесе кешенең, инсани затның үз эчендә гомер кичерә. «Убыр бу очракта нинди кешене сайлап ала соң?» дигән табигый сорау туа. Татарлар, башкортлар, казахлар Убыр шаукымлы ялгызак картларга һәм карчыкларга ияләшә, дип саныйлар. Бу Убыр-кеше — җанын шайтанга саткан сихерче дигән фикер дә бар. Себер татарларында Убырны сихерче-шаманның яисә үз-үзенә кул салган кешенең җан-рухы дип тә беләләр.

Татар мифы буенча Убыр, үзенең иясе (ияләшкән кешесе) йоклаган арада, аның башындагы (яисә култык астындагы) тишек аша тышка чыга,

Он принимает разные виды, ходит огненным колесом, свиньёй, чёрной кошкой, чёрной собакой. Ввиду того, что Убыр имеет наклонность влетать в печные трубы искрой, опытные люди советуют трубы держать постоянно закрытыми. Убыр (...) в особенности вреден для женщин, почему его стараются поймать и умертвить. Но поймать Убыра не так легко, потому что Убыр имеет способность быстро рассыпаться искрами и моментально исчезать. Один старик открыл секрет, как можно поймать Убыра. Оказывается, для этого следует только распороть на себе рубаху, тогда кажущийся огненный шар падает прямо к ногам человека, распоровшего рубаху, и превращается в того человека, от которого он отделился. Затем он начинает умолять, чтобы узнавший его тайну не бил его и не передавал никому о встрече с ним. При этом обещает не причинять никакого зла ни ему, ни его родным и знакомым, ни скоту его. Если в это время Убыра побить как следует, то утром «убырлы кеше» жалуется на боль в костях и долго хворает, так что из-за Убыра приходится переносить побои и человеку, спокойно спавшему на постели. (...)

өй эчендә йөри яисә утлы шар рәвешендә морҗа тишегеннән урамга чыга... Үзенең явыз ниятләрен гамәлгә ашыру өчен, корбанын эзли башлый, тапкач, аны үҗәтләнеп эзәрлекли — өркетә, куркыта, тотса баса башлый, буа, канын эчә... Шулай төннәр буе йөреп чыга; бу вакыт эчендә төрле рәвешләргә керә: утлы бөҗра (ут көлтәсе), кара мәче, кара эт, кара яисә чуар дуңгыз кыяфәтләре ала. Чуваш мифологиясендә утлы елан варианты да бар. Убыр кайчакта кеше кыяфәтенә дә керә.

Кешегә иялəшкән Убырдан иясенә бөтен холкы-табигате дә күчә дигән ышану бар. Бу кеше, Убырның үзе кебек үк, үтә дә комсыз, бик тә азгын, ашамчак була — күпме ашаганын да, туйганын да белми. «Убырның үзе туйса да, күзе туймый» дигән сүз әнә шуннан калган.

Кешегә иялəшкән Убыр төннәрен морҗа тишеге аша чыгып йөри, таң атар алдыннан гына, үз иясенә әйләнеп кайта икән. Шуны белгән кешеләр, бу явызның кереп-чыгып йөри торган урыны мич юллыгы булганлыктан, морҗаларны төнгә каршы ябып-томалап куя торган булганнар. Чыгып китә алмыйча яки кайтып керә алмыйча бәргәләнгән Убыр заты, беренче әтәчләр кычкыру белән ут көлтәсенә әверелеп, шартлап-чәчелеп юкка чыга, ди.

Если, говорит народная мудрость, взять деревянные черёмуховые вилы или вообще двухчастное дерево и, разломив разветвляющиеся части, отделить одну от другой, то Убыр обратится в человека, станет пред тобой на колени и станет просить о пощаде. В это время надо бить его сильнее, чтобы он больше не приходил. Почему народные легенды так подробно распространяются о том, в каком виде является Убыр, как его узнать и как избавиться от него? (...) Убыр признаётся крайне вредным существом. Действия его можно приравнять к действиям русских колдунов, оборотней и т. д. Люди, носящие в себе Убыра, бывают жадны и злы и, не довольствуясь своим, под разными видами выходят по ночам на кражу. Похищают они разные драгоценности. Помимо всего этого, Убыр может портить людей, наводить на них разного рода болезни. Одних делает сухорукими, другим прививает разные болячки и пузыри, иных превращает в кликунов и кликуш. Против последней болезни рекомендуется следующее средство. Когда человек начинает выкликать, надо снять с потной лошади хомут и надеть на того человека, который кличет; тогда этот человек выздоравливает и скажет, кто его испортил. (...)

# ХАҖИ УБЫРДАН КОТКАРА

Бер кеше хаҗдан кайтып килә икән. Кичкә калган бу. Өенә кайтып җитә алмагач, юлда очраган бер авылга кереп кунарга булган. Урамнан барганда, күңеленә хуш килгән бер өйгә туктап, фатир сорап, кунарга кергән. Юлчы хаҗи да булгач, хуҗа моны хуш күреп кабул иткән, алдына сый-хөрмәт куйган. Хаҗда булган хәлләрне сорашып, аны-моны сөйләшеп, болар йокларга ятканнар.

...Хаҗи бервакыт куркуыннан дерт итеп уянып киткән. Күзләрен ачып җибәрсә, ни күрсен — идән уртасында «тызз!..» итеп бер ут яна. Җиде төн уртасында! Бер караса, ул ут булып күренә, бер караса — хуҗа хатыны! Хаҗи, тынын да чыгармый, эчтән берөзлексез дога кабатлап ятуын белгән. Бер күтәрелеп караганда, теге утның җанлануын күреп калган. Менә ул ут дигәне шәүлә кебек шуышып киткән дә, кинәт кенә песи булып, мич юллыгына атылып менгән. Менгәч, шул минут эчендә ут булып морҗа аша чыгып юк булган. Хаҗи аның бары төтен булып сузылган,

# ХАДЖИ ИЗБАВЛЯЕТ ОТ ОБОРОТНЯ

Один человек возвращался из хаджа. Смеркалось. Не успев до темноты добраться до родного аула, он попросился на ночлег в первый понравившийся дом оказавшейся на пути деревни. Хозяин радушно и хлебосольно принял особого гостя, каким во все времена считается хаджи. Выслушав подробный рассказ о том, как прошёл хадж, поведав о своих повседневных делах, хозяева и хаджи легли спать.

...В какой-то миг хаджи вздрагивает от страха и просыпается. Открыв глаза, он видит, как посреди пола с треском и шипением горит огонь. Глубокой-то ночью! Некоторое время смотришь, это огонь, а через какое-то время — жена хозяина! Хаджи, не обнаруживая себя, знай читает беспрестанно молитвы. В какой-то миг подняв голову, он увидел, что пламя одушевилось. Вот огонь тенью прополз по полу и, вдруг обратившись





җемелдәгән койрыгын гына күреп калган.

Юлчы кеше куркып тормаган, тиз генә урыныннан торып, хуҗаны уятып, хәлне сөйләп биргән.

— Котыласың килсә, хатының кайтканчы, әнә урында ятып калган гәүдәсе өстенә тиз генә бер ак әйбер китереп капла, — дигән.

Хуҗа кеше, киштәдә торган ак намазлыкны алып, хатыны өстенә япкан. Хаҗи да, шул

в чёрную кошку, вспрыгнул на дымоход печи. Вспрыгнув на заслонку, оборотень в ту же минуту вновь обратился в пламя и вылетел в трубу. Хаджи успел увидеть только дымный след и поблёскивающий в темноте хвост.

Путник не испугался, споро встал с постели, разбудил хозяина и поведал ему об увиденном.

— Если хочешь избавиться от оборотня, нужно накрыть тело твоей жены белой тканью, — научил его хаджи.

гәүдә өстенә бар белгән догаларын укып өргән дә үз урынына барып яткан.

Менә бервакыт таң алдыннан хуҗа хатынның Убыр җаны кире әйләнеп кайткан, ди. Морҗадан ут булып — мич алдына, аннан тагы баягы кара песи булып идәнгә атылып төшкән дә, тыз-быз басып, ияләнгән гәүдәгә керергә килгән. Килсә, анда, хатын өстендә — өшкереп җәеп куйган ап-ак намазлык! Бар, хәзер кереп кара инде! Юлчы хаҗи да, теге хатынның ире дә, бу нишләр икән дип, астан гына карап-күзәтеп яталар икән. Кара песи, койрыгы пешкән кебек, намазлык тирәсендә әйләнепме-әйләнә, гәүдәгә берничек тә яңадан керә алмый икән.

Менә шулвакыт әтәч тә кычкырып җибәргән, кара песи дә ут булып тузгып юкка чыккан, ди.

Иртән торсалар, хатын тәмам терелгән, йөгерә-йөгерә коймак пешереп йөри икән. Ире дә бик шат. Убырдан коткарган өчен, ул юлчы хаҗины бик каты сыйлап, сәдакалар биреп җибәргән.

Хозяин, взяв с полки белый молельный коврик, намазлык, накрыл им тело жены. Хаджи, прочитав над телом все известные ему молитвы, лёг спать.

Незадолго до рассвета вернулась душа-оборотень жены хозяина дома. Сквозь трубу проникла огнём, затем, обратившись в недавнюю чёрную кошку, спрыгнула на пол и крутится юлой, не зная, как проникнуть в родное тело. Как проникнешь-то — хозяйка под намоленным белым намазлыком! Мощнейшая защита от нечистой силы! И хаджи, и муж хозяйки тихонечко наблюдали из-под одеял за кошкой, мол, что она будет делать, как себя поведёт. Чёрная кошка, словно ошпаренная, крутится вокруг накрытого намазлыком тела, но внедриться в него никак не может.

В эту секунду, говорят, и петух прокричал, и чёрная кошка, обратившись в пламя, исчезла.

Когда поутру мужчины проснулись, то увидели, что жена пришла в себя, проворно хозяйничает возле печи, оладьи печёт. И муж рад-радёшенек. За то, что избавил его жену от оборотня, он отблагодарил хаджи, сделал щедрое подаяние — садака.

# УБЫРЛЫ КАРЧЫК
# УБЫРЛЫ КАРЧЫК (БАБА-ЯГА)



«Үги кыз», «Әйгали батыр»,
«Камыр батыр»,
«Гөлчәчәк» әкиятләре (0+)

Сказки: «Падчерица», «Айгали-батыр»,
«Қамыр-батыр», «Гульчечек» (0+)

Татар мифологиясендә Убырлы карчык Убырдан аермалы карала, ул — бик үзенчәлекле мифик персонаж, тәмам кешеләштерелгән, хәтта нык кына әдәбиләшкән, әкиятләрдә күп очрый торган зат. Убырлы карчык, гадәттә, аулак урыннарда, кешеләрдән ерактарак яши. Андый урыннарга татарлар адашып кына килеп чыгалар. Убырлы карчык, гел кара киемнәр генә киюен исәпкә алмасак, башка карчыклардан әллә ни аерылмый, торган җире дә — гадәти авыл өе, урыс Бабаягалары яши торган тавык тәпиле йорт түгел. Гадәттә, аны сихергә яисә сихер кайтаруга мохтаҗ кешеләр эзләп таба.

Кешеләр Убырлы карчыкның кайда яшәгәнен ничек белгәннәр соң? Моның өчен күз кай якка төшә, шул якка карап чыгып китәргә кирәк икән.



*Яма уба — урман-тауларда яши торган япон сихерчесе.*

*Яма-уба — японская старуха-ведьма гор и лесов.*

*Каюм Насыри:*

Убыр-старухи всегда, по сказкам, живут в глуши и вдали от татарских жилищ, куда может попасть татарин, только сбившийся с дороги, когда идёт или едет. Живут они в избушках, только не на курьих ножках, как в русских сказках. Впрочем, бывают случаи, когда татары, имея нужду узнать о потере чего-нибудь важного, сами стараются отыскать убыр-старуху; но это бывают счастливцы, люди достойные, силачи, хитрецы. Как же они узнают о местопребывании убыр-старухи? А вот как: они пускаются в путь куда глаза глядят и после долгого странствования находят, наконец, на берегу озера женщину-красавицу, расчёсывающую себе волосы гребнем; она-то и сказывает, где живёт убыр. Но не подумайте, что это юха-кыз; юха та-



*Баба-яга — славян Убырлысы.*

*Баба-яга — старуха-чародейка, живущая в лесу.*

Кешеләр Убырлы карчыкның йортын төнлә ерактан ук ялтырап күренгән ут буенча табалар. Барып кергәндә, Убырлы карчыкның ашап утырган чагы була. Ул ут ашап утыра. Кергән кешенең «әссәламәгаләйкүм» дип сәлам бирүе мәҗбүри, югыйсә Убырлы карчык аны шундук йотачак. Әйе, Убырлы карчыкның төп шөгыле һәм явызлыгы — ул кешеләрне йота. Яисә йотып, кире чыгара. Бу очракта адәми зат бөтенләй үзгә кеше булып яңадан туа — йә ул яхшырып, изге бер затка әверелеп чыга, йә иң соңгы яман бәндәгә әверелә...

Миф-әкиятләрдән күренгәнчә, Убырлы карчык гадәти кешедән берни белән дә аерылмый. Аның Убыры да эчтән тышка чыгып йөрми инде. Өстәвенә ул алай ук тискәре зат та түгел. Юлын адашып Убырлы карчыкка килгән кеше ярдәм сораса, карчык аңа тылсымлы йомгак биреп, шуны җирдән тәгәрәтеп җибәрергә һәм йомгак артыннан барырга куша. Адашкан кешене йомгак тиешле җиргә илтеп куя, имеш.

тарину только вредит; а это жена диу-пэри, татарка, похищенная в детстве этим страшным и таинственным существом. Бывают, однако, случаи, когда дорогу к убыр-старухе показывает татарину не жена диу-пэри, обыкновенно сочувствующая человеку, а тот, кто уже был у старухи: в этом случае посещают убыр-старуху люди недостойные, сребролюбивые и сластолюбивые. Как те, так и другие, отыскивают жильё старухи всегда во время ночи, по огоньку, видимому издалека из избушки. При входе застают старуху за едою: она ест огонь. Вошедший непременно должен приветствовать старуху обычными словами: «эс-саляму галейкюм!» (мир вам!), иначе беда: съест его старуха. Однако же силачи, вроде тех, которые носят в дороге 40-пудовую дубину, обуты в 10-пудовые башмаки и перебрасывают через мечеть тройку с возницей и алпаутом (...), то есть людьми вообще тяжеловесными, никогда не дают салям убыр-старухе, и когда та, разъярившись, объявляет им, что она скомкает их, силачи (джигит, «молодец») одним взмахом сабли порешают жизнь убыр-старухи.

## ИЛЕКӘЙ БЕЛӘН УБЫРЛЫ КАРЧЫК

Борын-борын заманда яшәгән, ди, Илекәй исемле батыр. Сөйгән хатыны һәм кечкенә улы белән тату, бәхетле гомер кичергәннәр алар.

Бервакыт Илекәйнең улы авырып киткән. Өйдә нишләргә дә белмәгәннәр. Әмма терелтерлек шифа, дәва таба алмаганнар. Бала көннән-көн сулган, ябыккан. Йөзенә үлем төсе кергән. Ыру анасы Сагайдак әби им-томы да килешмәгән. «Балага гүр авыруы эләккән, тәкъдиргә буйсынмыйча чара юк...» — дигән карчык. Бераз уйланып торгач, үзалдына гына әйтеп куйган:

— Бер чара бар барын... Тик аны башкарып чыгып булмас шул...

Илекәй үтенеп-ялварып сораша башлагач, серне ачкан:

— Кара урман уртасындагы аланда, алачыкта Убырлы карчык яши. Менә шул сихерче карчыктан балаңны йоттырып, кире чыгарта алсаң, балаң терeләчәк. Шуны башкарып чыгарлык зирәклек таба алмасаң, икегез дә харап булырсыз...

Илекәй шунда ук юлга чыккан.

## ИЛЕКЭЙ-БАТЫР И КОЛДУНЬЯ

В давние-предавние времена жил, говорят, батыр по имени Илекэй. В счастье и радости жила их семья: он, его любимая жена, их маленький сын.

Однажды сын Илекэя тяжело заболел. Домашние не знали, как им быть. Но найти лекарство так и не смогли. Ребёнок день ото дня угасал, худел, с каждым днём всё больше становясь похожим на покойника. Не помогли и заговоры старейшины рода — бабушки Сагайдак. «В ребёнка вселилась смертельная хворь, придётся смириться с судьбой...» — только и сказала старуха. Немного подумав, она пробормотала под нос:

— Вообще-то один способ есть... Но осуществить его вряд ли удастся...

После долгих уговоров Илекэя она открыла секрет:

— В лачуге, что стоит на поляне посреди дремучего леса, живёт колдунья Убырлы-карчык. Вот если сумеешь сделать так, что эта колдунья проглотит и тут же выплюнет ребёнка, то он выздоровеет. Если не сможешь это организовать, то оба пропадёте...



Бик озак барган батыр. Бервакыт алда кара урман күренгән. Бик шомланып-шөбһәләнеп кенә булса да, Илекәй куе агачлык эченә кереп киткән. Керми чарасы да юк — кулында авыру бала ята ласа...

Бара торгач, барып җиткән бу Убырлы карчык йортына. Йорт диярлеге дә юк — шыксыз, килбәтсез, ярым җимерек бер алачык икән. Алачык эчендә тау кадәр мич утыра, ди. Анда дөрләп ут яна, зур казанда шыбырдап су кайнап тора, ди...

Ни хикмәт, Убырлы карчык бик җылы каршы алган юлчыларны.

— И-и, килеп әйбәт иттегез әле, адәм балалары. Ашарга гына җыенып йөри идем, шулпадагы ит азрак кебек иде, хәзер туйганчы ашарлык булыр инде... Әйдәгез, керегез, кер... Әнә шулпа да кайнап түгелеп бетә инде. Менә җулпыч, шуңа утыра тор, бераздан казанга төшереп җибәрермен, — диган ул Илекәйгә карап.

Илекәй җулпычка утырган утыруын, әмма үзе аякларын мичкә нык итеп терәп куйган. Убырлы карчык җулпычны ничек кенә этеп караса да, Илекәй казанга һич якын килми икән. Илекәй хәйләгә керешкән:

Илекэй тотчас же выехал.

Очень долго ехал батыр. Вот наконец впереди показался густой лес. Преодолевая страх и сомнения, он въехал в дремучую чащу. Деваться некуда — на руках лежит больной ребёнок...

Долго ли, коротко ли они ехали, однако добрались, наконец, до дома Убырлы. Такую лачугу домом-то называть грешно, невзрачная, полуразвалившаяся хибара. Внутри — огромная печь. В горниле — мощное пламя, в большом казане кипит-бурлит вода... «Похоже, суп варит эта лесная старуха, надо быть осторожным», — подумал Илекэй.

Удивительно, но Убырлы-карчык радушно встретила путников.

— О-о, как вы вовремя пожаловали, дети Адамовы. Я тут кушать было собиралась, да показалось, будто мяса в бульоне недостаточно, теперь-то уж точно наемся досыта... Давайте входите, милости прошу... А то вода уже через край котелка брызжет, того и гляди скоро вся выкипит. Вот лоток для муки — жулпыч, пока устраивайся на него поудобней, скоро я отправлю тебя в казанок.

Илекэй сесть-то сел на лоток, но ногами крепко упёрся в печь. Как ни старалась Убырлы-карчык подтолкнуть Илекэя к котлу, ничего у неё не по-



— Юк, булмый миннән, бик оста булгач, әйдә, алайса, үзең утырып күрсәт!

Ачуы чыккан Убырлыга шул гына кирәк тә — ялт итеп җулпыч өстенә менеп тә кунаклаган. Шуны гына көтеп торган Илекәй аны казанга шудырып төшереп җибәргән дә капкачын ябып та куйган. Кайнар шулпага эләккән карчык әллә нинди зәхмәтле тавышлар белән акырынырга тотынган:

— Әй, адәм актыгы! Ач тизрәк, пешеп үләм бит! Ни әйтсәң, шуны эшләрмен!

лучилось. Тогда Илекэй пустился в хитрость:

— Нет, не получается у меня, ты опытная, давай-ка научи, что делать, покажи, как нужно сесть!

Рассерженная Убырлы ловко вспрыгнула на жулпыч. Только и ждавший от старухи такого поступка Илекэй ловко отправил её в котёл и закрыл крышку.

— Если проглотишь и выплюнешь моего больного сына, заберёшь болезнь у моего кровинушки, больше не буду причинять тебе зла, и никому не расскажу о том, как ты опростоволосилась...

— Минем авыру улымны йотып төкерсәң, газиземнең сырхавын алсаң, чыгарырмын, — дигән Илекәй.

— Ярый-ярый... Мин... Мин... Барысына да... Риза... Риза...

Илекәй казан капкачын ачкан, кайнар шулпада пешеп үлә язган Убырлы карчыкны тартып чыгарган. Бераз аңына килгәч, карчык авыру баланы бүкән өстенә яткырып куйган. Аннары йөгереп килеп кабып та йоткан, күз ачып йомганчы косып та чыгарган. Идәнгә шап итеп түп-түгәрәк, тап-таза бер малай килеп тә төшкән!

Илекәй бу Убырлы йортыннан тизрәк китү ягын караган. Егәрлеге, сихере кабат кайтса, бу карчыктан котылам димә!

Ә Убырлы карчык үзенчә уйлаган: «Юк, кешеләргә башка тимим. Алардан гел кыенлык күрергә туры килә...»

— Ладно-ладно... Я... Я... На всё... Согласна... Согласна...

Илекэй открыл крышку казана и вытащил обваренную в кипятке, едва живую колдунью. Вытащил и с головой воткнул в бочку с холодной водой. «Чыж-ж-ж!..» — раздалось громкое шипение. Немного придя в себя, колдунья уложила больного ребёнка на пенёк. Затем, разогнавшись, проглотила свёрток, и почти мгновенно её стошнило. На землю шлёпнулся здоровый и упитанный мальчик!

Илекэй поспешил покинуть халупу Убырлы. Если попадёшь под мощные чары старухи, не рассчитывай скоро избавиться от них!

А Убырлы-карчык думала в свою очередь: «Нет, больше не буду обижать людей. От них одни неприятности случаются...» С этого дня она и вправду не обижала людей, даже если они и попадались ей, старалась обходить за версту.

## ЯЛМАВЫЗ
## ЯЛМАУЗ



«Дутан батыр» әкияте (0+), Р. Батулла: «Алып батыр маҗаралары» (6+), «Яхшылыкка явызлык» (0+)

Сказка «Дутан-батыр» (0+), Р. Батулла: «Приключения Алып-батыра» (6+)

Ялмавызны татарлар мәһабәт, йомры гәүдәле, зур корсаклы, елан койрыклы, маңгаенда калкып торган зур сыңар күзле, зур авызлы, калын иренле, еланныкы кебек озын телле килбәтсез карчык итеп күз алдына китергәннәр.

Ялмавыз, йөргәндә, җир өстендә гарасат, җилдавыл куптарып йөри, теләсә, озын теле белән җиде чакрым тирә-ягындагы бөтен нәрсәне ялмап йота ала. Ялмавыз атамасы да шуннан килә булса кирәк — ялмый торган авыз, ялма авыз. Ялмавызның сулышытыны агулы, имеш. Ул үзенең тынын гына өрсә дә, кеше аңын югалтып егылырга мөмкин икән... Тыны белән агулый, аннары йота.

Кыскасы, Кеше, Дию, Аждаһа-елан, Албасты, Убырлы карчык сыйфатларын бергә берләштергән рухны татарлар «Ялмавыз» дип атыйлар.



*Желмогуз кәмпер — казахларда җиде башлы ялмавыз.*

*Желмогуз кемпир — казахский семиглавый ялмауз.*

Ялмауза представляют в виде уродливой одноглазой и толстогубой старухи крупного телосложения, с большим животом, а также хвостом и языком, как у змеи.

Ялмауз передвигается по земле, поднимая бурю, заглатывая всё, что находится на расстоянии семи вёрст, при помощи своего длинного языка. Отсюда и произошло само название (с тат. «ялману» — облизывать, «авыз» — рот). У Ялмауза ядовитое дыхание, от которого человек может потерять сознание.

Словом, Ялмауз — это дух, сочетающий в себе качества Человека, Дива, змея Аждахи, Албасты и Убырлы карчык. Но, в отличие от Убырлы, Ялмауз более жестокий: проглатывает жертву и не выплёвывает.



*Тифон — греклардагы баш чүмечендә йөз аждаһа башлы, ут күзле мифик персонаж.*

*Тифон — мифическое существо у греков, имеющее сто драконьих голов на затылке и огненные глаза.*

# АЛТЫНДУГА БАТЫР

*(Башкорт халык әкиятеннән)*

...Атна буе кунак булгач, Алтындуга батырның агалары кайтырга җыена башладылар, ди. Кызның атасы, кырык ат җиктереп, арбалар тулганчы алтын, көмеш, кыйммәтле әйберләр, җиһазлар төятте. Кияүләре йортына икенче бер юлны өйрәтеп җибәрде, ди.

— Юлда бер урында бик матур җимеш бакчасы булыр. Ул бакча янында туктамагыз, җимешенә тимәгез, юкса һәлак булырсыз. Ул бакча — җиде башлы Ялмавызныкы, — дип әйтте, ди.

Тегеләр, ярар-ярар, дип, сиксән дуга булып юлга чыктылар. Менә бервакыт әлеге бакча турысына килеп җитәләр болар. Бу бакча күз алгысыз матур, ди. Болар туктамыйча чыдый алмыйлар.

— Без бит йөзгә якын. Бу кадәр кешене нәрсә эшләтер дисең, — диешеп, арбаларыннан төшеп, дәррәү җимеш ашый башладылар, ди.

# АЛТЫНДУГА-БАТЫР

*(Из башкирской народной сказки)*

...Прогостив неделю, братья Алтындуги-батыра засобирались домой. Отец невесты снарядил сорок подвод, загрузил их до краёв золотом, серебром, прочими драгоценностями и необходимыми в быту вещами. Научил, как проехать другой дорогой к дому зятя.

— В одном месте натолкнётесь на роскошный фруктовый сад. Там не останавливайтесь, к фруктам не прикасайтесь, иначе умрёте. Это сад семиглавого дракона Ялмауза, — наставлял он.

Те, согласно покивав головами, в восемьдесят дуг тронулись в путь. В какой-то момент они доехали до того сада. Сад такой роскошный, глаз не отвести. Они не смогли удержаться и остановились.

— Нас ведь почти сотня. Что он сможет сделать с таким количеством народа? — соблазняя друг друга, они слезли с телег и начали бессчётно рвать дары сада.





Ашап туйгач, китәргә булганнар иде, җиде башлы Ялмавыз килеп чыкты да:

— Сез минем ничә еллар саклап үстергән бакчамны бетергәнсез, мин сезне җибәрмим! — дип әйтте, ди.

Болар ялынып карыйлар — теге һич җибәрми, ди. Ялмавыз ничек булса да Алтындуга батырны монда китереп, аның аркылы үзенә Каф тавы артында яшәүче Дию кызын алдыртмакчы була икән. Шуңа күрә дә Алтындуга батырның кәләшен алып калырга уйлаган. Тегеләр һаман ялынгач:

Наевшись досыта, они собрались было трогаться в путь, но на их беду объявился семиглавый дракон Ялмауз:

— Вы разорили мой сад, за которым я ухаживал много лет, я вас никуда не пущу, — сказал он.

Те умоляют его отпустить, но Ялмауз непреклонен. Он хочет любым способом выманить сюда Алтындугу-батыра и с его помощью доставить к нему живущую за семью морями, за семью горами дочку Дива. Потому-то он и задумал оставить у себя невесту Алтындуги. На непрекращающиеся мольбы остальных он ответил:

— Ярый, сезне җибәрәм, ә менә Алтындуга батырның кәләшен алып калам, — ди.

Ялмавыздан котлары очкан агалары:

— Бу тикле кешене һәлак иттергәнче, бер кеше икән, биреп китик, — дип, Алтындуга батырның кәләшен калдырып киттеләр, ди.

Болар кайтуга, Алтындуга батыр: «Кәләш килә», — дип утыра, ди. Кайтсалар, Алтындуга батырның кәләше юк. Агалары:

— Кәләшеңне юлда җиде башлы Ялмавыз алып калды, — диләр.

Алтындуга батыр, күп уйлап тормыйча, кылычын ала да, җәяүләп, Ялмавыз торган җиргә китә. Барып җитә, җиде башлы Ялмавыз килеп чыга, ди. Алтындуга батыр үзенең кәләшен сорый.

Ялмавыз:

— Мин аны болай гына бирмим. Каф тавы артында бер Дию кызы бар, шуны миңа алып кил, шуннан соң бирәм, — ди.

(Моннан соң Алтындуга батырның, өч юлдашы белән бергә, патшаның шартын үтәве, аның кызын алуы, диюләр һәм патшаның үзе белән алышып, аны җиңеп, кайтыр юлга чыгуы хакында сөйләнә. — *Г. Г.*)

— Ну хорошо, вас я отпущу, но невесту Алтындуги оставлю у себя.

Напуганные Ялмаузом братья приходят к общему мнению:

— Погубить одного человека вместо такого количества людей, давайте так и сделаем, — и, оставив невесту Алтындуги дракону, уезжают.

Услышав шум подвод, Алтындуга подумал: «Невеста едет». Но невесты в обозе не оказалось.

— Невесту твою семиглавый дракон Ялмауз забрал, — объяснили ему братья.

Алтындуга-батыр, недолго думая, подпоясался мечом и пешком отправился к жилью Ялмауза. Добрался Алтындуга-батыр до жилья Ялмауза, тот вышел ему навстречу. Алтындуга спросил его о своей невесте.

— Просто так я её не верну. За семью морями, за семью горами живёт дочка Дива, приведёшь её ко мне, тогда и верну тебе невесту, — отвечает Ялмауз.

(Далее речь о том, как Алтындуга-батыр с тремя попутчиками, выполнив все условия патши, забрали его дочь, сразившись с дивами и самим патшой, победили их и отправились в обратный путь. — *Г. Г.*)

# ӨРӘК
# УРЯК (ПРИЗРАК)

«Йөрәкле җегет» әкияте (+0)



Сказка «Храбрый джигит» (+0)

Өрәк — Идел буе, Урал төркиләрендә киң таралган мифик персонаж. Ул — үз үлеме белән үлмәгән кешеләрнең җир өстендә бәлтерәп йөргән әрвахы.

Өрәкне төннәрен озын ак киемгә төренгән хәлдә, тавыш-тынсыз гына йөргән вакытында, кайчакта иңрәп елаган яисә ачы тавышы белән моңлы итеп җырлаган чагында күрәләр. Ул буйга озын, нәзек, ябык була, кайчагында кәфенен дә башыннан салмый, какча, ак йөзен генә ачкан була. Көчләп үтерелгән кешенең рухы әнә шулай, үзенә тынычлык таба алмыйча, адашып йөри.

Өрәк кешеләргә турыдан-туры зыян салмый. Әмма ул, төннәрен каршысына килеп чыгып яисә артыннан калмыйча ияреп барып, йә булмаса, иңрәп елау-ыңгырашулары белән куркытып, кешенең котын ала.



*Эль Кукуй (яки Куко, Кока, Кука, Коко) — португал өрәге.*

*Эль Кукуй (или Куко, Кока, Кука, Коко) — португальский призрак.*

*Яков Коблов:*

Под именем уряка у татар разумеется баснословное существо, преимущественно живущее там, где был убит человек, на местах, обагрённых человеческой кровью. Татары стараются на далёком расстоянии обходить могилы умерших насильственной смертью людей и видят уряка только издалека или только слышат его раздирающий душу вопль. Если уряк находится вблизи человека и не желает отстать от него, то освободиться от него можно только нехорошими бранными словами...

*Каюм Насыри:*

Также рассказывают татары, что уряк может преобразиться в облако. Если бы прохожий татарин и не увидал сразу на пути мёртвое тело, то раздирающий клик уряка непременно обратил бы его внимание на это тело.



*Уруакан — әрмән мифологиясендә өрәк.*

*Урвакан — дух умершего в армянской мифологии.*

## ӨРӘК ҺӘМ АНЫҢ АНАСЫ

Бер авылны җиде ел буе бер Өрәк эзәрлекли. Ике авыл арасында җир бүлешкәндә күрше авыл кешеләре тарафыннан үтерелгән егет өрәге икәнен дә халык төгәл белә. Ызан хакындагы ызгыш чыккан басулар да ничә ел инде уңыш бирми, бозлы яңгыр яисә җил-давыл афәтенә очрап, кысыр туфракка, кара җиргә әверелә. Кара төндә аны чәнчеп үтергән өч кешенең өчесе дә инде исән түгел. Шушы Өрәк каршына килеп чыгып, авылның берничә кешесе телсез калды, күпме кеше тотлыгып сөйләшә башлады...

Бу бәлагә түзәрлекләре калмагач, бер көнне авыл кешеләре теге Өрәк-егетнең авырып яткан әнисе янына барганнар.

— Син бит аның анасы, күреп әйт әле малаеңа, безне тынычлыкта калдырсын, ә?! — дигәннәр.

Бала кайгысыннан иртә картайган ана төнге юлга чыгып йөри башлаган. Җиденче төн дигәндә, ул, ап-ак кәфенгә төренеп, җир өстеннән атлап түгел, бераз калкынып, очып-йөзеп йөри торган улының шәүләсенә тап булган.

## ПРИЗРАК И ЕГО МАТЬ

Одну деревню на протяжении семи лет изводил-донимал призрак. Все знают, что это призрак Кабира, убитого жителями соседнего аула при делёжке земли. Те поля, во время делёжки которых случилось убийство, много лет не дают урожая, то град побьёт всходы, то ураганный ветер унесёт плодородный слой, превращая пашни в бесплодные наделы. Трое парней, напавших на Кабира тёмной ночью, уже и сами расстались с жизнью. Несколько сельчан, столкнувшихся с призраком, потеряли дар речи, кто-то стал заикаться...

Окончательно потеряв терпение от истязательств призрака, в один из дней сельчане пришли к его больной, прикованной к постели матери.

— Ты же его мать, найди сына и скажи ему, чтобы не истязал нас, а?! — попросили они.

От горя состарившаяся до срока мать, прихрамывая, стала выходить по ночам на улицу. На седьмую ночь она столкнулась с завёрнутым в белый





— Улым!.. — дигән дә һушы китеп егылган ана кеше.

Өрәк тә яшен тизлегендә килеп җиткән:

— Әни!..

Ана кеше аңына килгәндә, янында улы утыра, имеш. Ак кәфенлек бөркәнгән, нәкъ күкрәк турысында — кан эзләре. Йөзе ачык түгел, бөркәнгән кәфенлек ышыгында ике ал тап — күзләре генә күмердәй янып-җемелдәп тора...

— Әни!..

— Әү, балам...

— Әни, нигә мине үлмәгән килеш күмдегез? Сез күмгәндә, йөрәгем тибә иде бит әле...

— Нишлибез соң, улым?

саван призраком, не шагающим по земле, но, чуть наклонившись, тенью парящим над землёй.

— Сынок!.. — вымолвила мать и без чувств рухнула на землю.

Призрак молниеносно подлетел к ней:

— Мама!..

Когда мать пришла в себя, сын сидел подле неё. С ног до головы завёрнут в белый саван, посередине груди следы крови. Лицо закрыто, за пологом савана два красных пятна — это глаза горят огнём, поблёскивают...

— Мама!..

— Ау, сынок...

— Мама, зачем же вы меня похоронили заживо? Когда вы меня хоронили, сердце моё ещё билось...

— Бер юл бар...
— Нинди юл ул, улым?
— Син ача аласың миңа ахирәт юлын...
— Ничек?
— Син бакыйлыкка күчкәндә, мин сиңа ияреп китә алам...
— Син миңа үләргә кушасыңмы, улым?
— Әйе, әнием. Мин бит Өрәк, мин үлеләр илендә яшим. Синең үлем дә минем өчен шатлык кына булачак. Син минем янда булсаң, юл күрсәтсәң, мин бәхетле булыр идем...

Тагын җиде көннән ана, фанилыктагы гомерен тәмамлап, җан тәслим кыла. Аның җәсәденә кадәр авыл юлларында, зират буйларында Өрәкне күргән кеше булмый. Ана кеше җан очырып кабергә кергәннең өченче көнендә генә зират өстендә ниндидер ут шәүләсе кабынып сүнгәнен күрәләр. Өрәк тә мәңгелеккә югала.

— Что будем делать, сынок?
— Один способ есть...
— Какой, сынок?
— Путь в загробный мир для меня можешь указать ты...
— Как?
— Когда ты будешь переселяться туда сама, я смогу увязаться за тобой...
— Ты советуешь мне умереть, сынок?
— Да, мама. Я ведь призрак, я живу среди мёртвых. И твоя смерть стала бы для меня радостью. Если ты будешь рядом со мною, если покажешь дорогу, то я буду счастлив...

Ещё через семь дней мать преставилась. Все дни до её похорон никто не видел призрака ни у дорог, ни у кладбища. На третий день после похорон матери люди заметили, как над кладбищем вспыхнуло и погасло непонятно откуда взявшееся свечение. И призрак навсегда исчез.

# ДИЮ
# ДИВ

«Утыз ул», «Нурсылу», «Дию патша», «Ак бүре», «Мәрмәр тавы башында», «Таңбатыр», «Алтын алма», «Өч дус» әкиятләре (0+)



Сказки «Тридцать сыновей», «Нурсылу», «Див-царь», «Белый волк», «На гранитной горе», «Тан-батыр», «Золотое яблоко», «Три друга» (0+)

Дию — татарларга фарсы мифологиясеннән кергән явыз рух. Ул кешеләрнең тискәре сыйфатларын, табигатьнең бәла-казалы күренешләрен образлы гәүдәләндерә.

Диюнең сурәте төрледән-төрле: бер башлы, кайчакта гына берничә башлы (күбрәк — өч яки җиде башлы), бер башлылары сыңар күзле (анысы да маңгаенда урнашкан, чынаяк кебек бүлтәеп чыгып тора), шәрә, йөнтәс, кайчакта, кешеләштерелгән вариантында — сәләмә кием кигән, озын куллы, озын бармаклы, каты, тимер тырнаклы...

Дию пәрие, гадәттә, Каф тау артында, җир астында яки диңгез астында (бик сирәк кенә — диңгездәге утрауда) яши. Анда аларның үз патшалыклары, мәһабәт сарайлары бар. Кайчакта Дию пәрие җир өстенә чыгып йөри, әмма ул кеше күзенә бик сирәк күренә.



*Яков Коблов:*

Так же, как Джинны, Дивы в разных видах являются людям. При этом они очень враждебно относятся к человеку и стараются погубить его. Между тем как Джинны не приносят существенного вреда человеку, Дивы похищают татарских девиц и затем женятся на них, уводят татар к себе и там разными способами губят их. Только молодцы-богатыри из татарских юношей смело и безбоязненно идут к Диву в гости — выручать свою сестру или родственницу и, если нужно, убивают его [Дива]. В случае недостатка силы татарин, попавший в гости к Диву, спасается от него хитростью.

*Дэвлар — иран, әрмән, грузин, даг мифологиясендә алыплар.*

*Дэвы — великаны иранских, армянских, грузинских, дагестанских народов.*



Дию пәрие, К. Насыйри фикеренчә, — татарга дошман зат; ул кешеләргә өч төрле зыян сала:

1. Дию кечкенә кызларны урлап алып китә дә, үсеп җиткәч, хатынлыкка ала;

2. Дию татарны мыскыл итә; аның дусты яки берәр яхшы кеше кыяфәтенә кереп, үз шәһәренә алып китә дә, сыйламакчы булып, аның алдына начар ашлар китереп куя;

3. Дию үзенең кунакка чакырып китергән татарын ничек тә булса һәлак итәргә тырыша: мунча ягып, аны мунчага алып бара, кунак чишенгәч, якты йөз күрсәткән булып, үзе юындырмакчы була. Татар риза булып, аркасы белән әйләнгәч, Дию аны себерке сабы белән кыйнап үтерә дә мунча ләүкәсе астына күмеп куя... Ләкин кайбер батырлар Диюдән алдатмыйлар, кырык потлы күсәкләрен күтәреп, Дию артыннан киләләр дә явыз затның җилкәсенә кундыралар...

*Каюм Насыри.*

Дивы живут в своих городах, имеют царства под землёю и морем, и невидимо — на земле. На нашей планете, между прочим, они живут и владеют теми местами и там, где положен клад; да и сами кладовые вещи, обыкновенно не благоприобретённые, от продолжительного пребывания в земле порождают дивов, подобных во всём своим предкам. (...) Нужно заметить, что они непримиримо враждебны татарину: 1) они похищают девочек; до возраста держат их у себя и тогда на них женятся; 2) дивы ругаются над татарином: например, в образе какого-либо знакомца или добряка див уводит татарина в свой город, в доме у себя угощает его; но если татарин скажет: «бисмилля» (во имя Бога!) перед вкушением пищи, поставленной дивом, то явно будет татарину, что это не пища, а лошадиный помёт; 3) див непременно постарается зазванного к себе в гости татарина свести с лица земли и обыкновенно так: прикажет жене истопить баню, поведёт в неё гостя, и когда тот разденется, див предложит ему с видимым радушием услуги свои — помыть, испарить, а когда татарин подставит спину, то див забьёт его комлем веника до смерти и мёртвого зароет под полком своей бани. Однако див боится «бисмилля»; хотя редко, но могут его побеждать джигиты (...).

# АЛТЫНЧӘЧ ҺӘМ ДИЮ

Бервакыт җир астында яшәүче диюләр кешеләрнең утларын урлаганнар. Утсыз яшәү кыен булганга, кешеләр, җыен җыеп, шобага салып, өскә чыккан Шәвәли исемле кешене диюләрдән ут алырга җир астына төшерергә карар кылганнар. Атасының борчылып йөрүен күреп, Шәвәлинең кызы Алтынчәч ут эзләргә үзе барырга булган.

Алтынчәч, җиде көнлек ризык алып, юлга чыгып киткән. Өч көн дигәндә, кара урман уртасында диюләр төшеп-менеп йөри торган коены барып та тапкан. Кое читендәге имән баганага аркан бәйләп, очын аска ташлаган. Өч көн, өч төн төшкәч, Алтынчәчнең аягы каты җиргә тигән. Ул шулай җир асты дөньясында пәйда булган. Бу дөньяның үз кояшы, үз ае бар икән. Анда да елгалар ага, урманнар шаулый, кошлар оча, җәнлекләр, хайваннар яши икән. Шулай да бу дөнья куркынычрак, караңгырак икән.

Кыз якында гына бер йорт күреп алган. Барып караса, анда бер Дию карты ипи салып йөри, ди. Әмма һич кенә дә икмәге уңмый, ди. Шунда Алтынчәч түзмәгән, Диюгә тәмле итеп икмәк пешереп биргән.

— Кем син, каян чыктың? — дип сораган Дию Алтынчәчтән.

# АЛТЫНЧЕЧ И ДИВ

Однажды дивы, живущие под землёй, украли у людей огонь. Устав от жизни без огня, люди собрали сход и потянули жребий, кому спускаться под землю за огнём. Идти выпало Шавали. Увидев, как отец озабоченно ходит по двору, не находя себе места, его дочь Алтынчеч решила сама пойти на поиски огня.

Собрав еды на семь дней, Алтынчеч тронулась в путь. Через три дня она отыскала в дремучем лесу колодец, через который поднимались-спускались дивы. Привязав к дубовому столбу возле колодца один конец аркана, другой бросила в скважину. Через три дня и три ночи спуска нога Алтынчеч ступила на что-то твёрдое. Так она оказалась в подземном мире. У этого мира своё солнце и своя луна. Там тоже текут реки, шумят леса, летают птицы, живут звери и домашний скот. Однако этот мир более пугающ, более тёмен.

Девушка разглядела неподалёку одну избу. Вошла она внутрь и видит, что старый-престарый Див пытается испечь хлеб. Но хлеб ему никак не



— Мин — Алтынчәч, Җирдән сезнең дөньяга утка төштем. Бирә алмассызмы?

— Бирәм, ник бирмим ди... Тик шартым бар — син минем хатыным булып калырсың.

Кыз да төшеп калганнардан түгел икән.

— Мин риза, тик әти-әнидән рөхсәт сорарга кирәк булачак...

Менә алар, ут алып, аркан буйлап өскә үрмәли башлаганнар. Иң беренче булып өскә Алтынчәч менгән. Менгән дә, Дию карты кое читенә ябышып өлгергәнче, имән баганага бәйләнгән бауны чишеп җибәргән.

Дию кабат үз дөньясына төшеп киткән. Ә Алтынчәч әтисе белән әнисенә яшәү өчен бик тә кирәкле утны алып кайтып биргән.

удаётся. Не вытерпела Алтынчеч смотреть на мучения старика и испекла Диву вкусный хлеб.

— Кто ты, откуда? — спросил Див Алтынчеч.

— Я — Алтынчеч, к вам спустилась с Земли в поисках огня. Не дадите?

— Дам, почему бы не дать-то... Но у меня есть одно условие — ты станешь моей женой и поселишься здесь.

Однако девушка оказалась не робкого десятка.

— Я согласна, только нужно у родителей благословение получить...

Вот они, взяв запас огня, начали подниматься по аркану. Первой на поверхность вышла Алтынчеч. Вышла и, пока Див не успел ухватиться за край колодца, отвязала от дубового столба аркан.

Див снова улетел в подземный мир. А Алтынчеч принесла столь необходимый для счастливой жизни своих родителей огонь.



# УРМАН ИЯЛӘРЕ. ШҮРӘЛЕ
## ШУРАЛЕ

Г. Тукай: «Шүрәле», «Шүрәле каргаган авыл» әкияте (0+)



Г. Тукай: «Шурале», сказка «Деревня, проклятая Шурале» (0+)

Су иясе, Йорт иясе булган кебек, Урман иясе дә бар.

Татарстанның Дөбъяз, Арча якларында кәрлә буйлы урман картларын татарлар элек-электән Шәке (Шекә) яисә Шәке пәриләре дип йөрткәннәр.

Шәкенең буе — бер терсәк, сакалы — ике-өч терсәк. Ул ак чәчле, ак сакаллы (кайчакта — җирән), җыерчыкланып беткән йөзле, зур түгәрәк күзле бер мифик зат рәвешендә сурәтләнә. «Шәке» атамасын күрше мари төбәге мифлары белән бәйләп карарга мөмкин. Марилар урман сарыгын, урман кәрләсен Шика яисә Шига дип йөртәләр.

Шәкенең иң төп эше — урманда агачларны, куакларны барлап тору, аларның исәбен алып бару. Шәке урманны рәнҗеткән кешеләрне төрле юллар белән урманнан чыгарып җибәрергә тырыша: сизмәстән генә килеп, балталарын урлап китә, йөк бауларын кисә, атларын куркытып җибәрә, арба кендеген яисә тәгәрмәч чөен алып яшерә...



*Лошолич — чегән Шүрәлесе.*

*Лошолич — цыганский Шурале.*

*Яков Коблов:*

Показываются людям Шуряле большей частью весной и летом во время восхода и захода солнца. При встрече с человеком Шуряле называется по имени, иногда притворяется сбившимся в лесу с дороги и просит о помощи. Иногда плачет, а иногда весело разговаривает и смеётся, так что кого угодно может расположить в свою пользу. На вопросы Шуряле никогда не отвечает, но сам любит спрашивать. Никогда не следует ему показывать зубы во рту. Как только Шуряле увидит зубы у человека, начинает его щекотать, и щекочет до смерти. Имея длинные, крепкие,



*Хульдра — скандинавия мифологиясендә койрыклы урман сылуы.*

*Хульдра — лесная красавица с хвостом в скандинавской мифологии.*

Пермь татарлары, Себер татарлары мифологиясендә очрый торган Урман иясе Ярымтык (Ярым җык, Ярты агач-кеше) дип атала. Мәҗүси ышанулар буенча, җир йөзендәге бөтен кеше дә шушы Ярымтыктан яралган. Бу түбән рух — гарип рух; ул ярым гәүдәле, гәүдәсе бөтен булган очракта да, бер күзле, бер куллы, сыңар аяклы; Ярымтыкның аяк йөзлеге артта диган сүзләр дә йөри...

Габдулла Тукайның Шүрәлесен кем генә белми икән?! Тышкы кыяфәте белән Шүрәле кешегә охшаган. Әмма куллары озын, бармаклары ике-өч карыш. Сакал-мыегы бар, тәне йөнтәс, ләкин хайваннарныкы кебек куе, озын йонлы түгел. Кечкенә башлы, кылыч борынлы, алга чыгып торган зур күзле, озын колаклы, кайчакта маңгай уртасында җыйнак кына мөгезе дә бар. Аның Урман тәңресе белән дә, Урман иясе белән дә уртаклыгы юк. Шүрәленең ике шөгыле һәрвакытта телгә алына — ул адаштыра һәм кытыклап үтерә. Әмма...

Әмма Шүрәле ялгыз кешеләрне генә адаштыра. Ялгыз кешенең генә юлына аркылы төшә. Ике кешегә, хәтта эт иярткән ялгыз кеше булса да, Шүрәле якын килми.

как бы оловянные пальцы, Шуряле очень любит это занятие — щекотать людей. Немало людей и животных погибло от щекотания Шуряле. Каждому встречному Шуряле предлагает играть в «кытыклы-мытыклы» (щекотку). Игра эта очень опасная. Сколько бы человек ни кричал, ни умолял о пощаде, Шуряле не перестанет его щекотать до тех пор, пока человек не умрёт. Умудрённые опытом люди говорят, что для спасения от Шуряле нужно бежать к ручью или реке и перескочить через неё. Шуряле боится воды и, не имея возможности перейти ручей или речку, спрашивает: «Где начало речки?» Нужно показывать ему не начало реки [исток], а низ [наиболее полноводное и широкое русло]...

## АЙСЫЛУ БЕЛӘН ШҮРӘЛЕ

Бик матур бер җәйге көндә Айсылу исемле кыз урманга барган. Бу җәй урманнарда җиләк күп булган. Җиләк җыю белән мавыгып, кыз үзенең адашуын сизми дә калган. Йөри-йөри арып-алҗап беткән, ләкин авылга алып чыга торган сукмакны һаман таба алмаган ул.

Шактый йөргән Айсылу урман буйлап. Ниһаять, аңлап алган: һаман бер урында әйләнеп йөри икән бит ул!

Нишләргә, кая барырга белми торганда, Айсылу каршына бер карт килеп чыккан. Бик сәер карт булган ул. Сәләмә киемле, бөкре гәүдәле, бөтен йөз-башын, кул-аякларын, тәнен йон баскан, маңгай турысында мөгез кебек бер шеш бар, озын, кәкре борынлы, күмер күзле, җиргә тия язып торган озын куллы, озын бармаклы, тырнаклары җиту...

Әлбәттә, Айсылу шунда ук: «Шүрәлеме әллә бу?» — дип, шикләнеп-шөбһәләнеп уйлап куйган. Әмма бераздан тынычланган. Беренче карашка гына шулай килбәтсез, ямьсез икән бу «урман кешесе». Әнә бит Айсылуның каршысына ук килеп, көлеп-елмаеп тора! Үзе бертуктаусыз сораша:

## АЙСЫЛУ И ШУРАЛЕ

Прекрасным летним днём девушка по имени Айсылу отправилась в лес. Увлёкшись сбором ягод, не заметила она, как заблудилась. Долго проискала Айсылу обратную дорогу, из сил выбилась, но так и не нашла.

Долго брела по лесу Айсылу.

Наконец, поняла: она ходит по кругу!

Охваченная тревожными раздумьями Айсылу лишь в последнюю секунду заметила, что вплотную к ней подошёл старик. Очень странный старик: одетый в грязное рваньё, горбатый, всё его тело покрыто густой шерстью, на лбу большая шишка, похожая на рог, большой, крючковатый нос, чёрные, словно угли, глаза, длинные, свисающие почти до земли руки, узловатые, длинные пальцы, безобразно отросшие ногти...

Конечно же, Айсылу тут же заподозрила: «Уж не Шурале ли это?» Но вскоре успокоилась. Лишь на первый взгляд безобразным кажется этот «лесной человек». Вот же он, стоит возле Айсылу и беззаботно улыбается! А сам беспрестанно расспрашивает её:



— Син кем? Кем кызы? Кайсы авылдан? Әтиең кем? Әниең кем? Сеңелләрең бармы? Энеләрең бармы? Әби-бабаң исән-саумы? Үзең кая барасың? Нигә ялгызың йөрисең?..

Айсылу җавап бирә-бирә арып беткән. Үзе эчтән генә уйлый икән: «Шүрәле сорашырга ярата, диләр иде, сораша-сораша хәлләрен алгач, корбаннарын кытыклап үтерә, имеш»...

Шулвакыт Айсылу үзе дә Шүрәледән сораша башлаган.

Шүрәле сорашканны яратмый. Сорау биргән саен, сихере кими икән аның... Ул түзгән-түзгән дә: «Эшләрем күп», — дигән булып, ашыгып китеп барган.

— Кто ты? Чья дочь? Из какого аула? Кто твой отец? Кто твоя мать? Есть ли у тебя сёстры? Есть ли у тебя братья? Живы ли твои бабушки-дедушки? Куда ты идёшь? Почему в одиночестве бродишь по лесу?..

Айсылу устала отвечать на бесконечные вопросы. А сама думает: Шурале, рассказывают, любят вначале измотать расспросами, а потом начинают до смерти щекотать обессиленных жертв...

Решила Айсылу обороняться от нападок Шурале его же методом. Стала задавать один за другим вопросы.

Шурале не нравится, когда его расспрашивают. Оказывается, с каждым вопросом сила его волшебства



«Уф, котылдым бугай», — дип уйлаган кыз. Бераз хәл алып, торып кына киткән икән, каршына тагын килеп чыкмасынмы теге Шүрәле?! Килеп чыккан да кызга мәзәк сөйләргә керешкән. Шулкадәр мәзәк итеп сөйли икән: Айсылу көлеп җибәрүдән чак-чак тыелып тора, ди. Әгәр авызыңдагы барлык тешләреңне берьюлы күрсәтеп көлсәң, Шүрәле шундук кытыклый башлаячак...

Айсылу, көлмәс өчен, былтыр үлгән кәҗә бәтиләре хакында уйлаган, шунда кызның күзләреннән яшь тама да башлаган. Моны күреп, Шүрәле тагын юкка чыккан.

Кытыклап күңеле булмыйча торып, Шүрәле аны җибәрәме соң инде! Шулай дип уйлавы булган, теге урман заты тагын пәйда булган:

— Әйдә качышлы уйныйбыз. Син качасың, мин куам. Тотсам — кети-кети уйныйбыз, килештекме? — ди икән.

«Беткән баш беткән инде. Качып карыйм», — дип уйлаган Айсылу. Алан уртасында үсеп утырган мәһабәт бер имән агачына күрсәтеп:

уменьшается... Терпел-терпел Шурале расспросы девушки и спешно ретировался, заявив: «У меня дел много».

«Уф, избавилась, кажется», — подумала девушка. Не успела она подняться после короткого отдыха, а Шурале уже тут как тут! Подскочил и начал веселить девушку смешными рассказами. С таким азартом рассказывает Шурале свои мэзэки, что Айсылу еле сдерживается, чтобы не рассмеяться в голос. «Если обнажишь все зубы в улыбке, Шурале тут же начнёт щекотать», — говорила ей бабушка.

Чтобы не рассмеяться, Айсылу стала вспоминать умерших в прошлом году козлят. Бедняжки отбились от стада, и их задрал волк... Не успела она подумать о козлятах, как из её глаз покатились слёзы. Увидев такое, Шурале чуть с ума не сошёл. Постояв немного рядом, он снова убежал в дремучий лес.

Похоже, не отпустит её Шурале, пока не насладится щекотанием. Не успела она так подумать, как лесной житель вновь предстал перед ней:

— Давай в прятки поиграем. Ты прячешься, я ищу. Если найду — защекочу, согласна? — предложил Шурале.

«Была не была, — подумала девушка, — попробую спрятаться».

— Сперва пересчитай все листья на этом дереве, — указала она на

— Менә шушы имәндәге яфракларны кайчан санап бетерәсең, шунда гына мине эзли башлыйсың... Кара аны, алдама!.. — дигән.

Айсылу урман куелыгына йөгереп кереп киткән, Шүрәле яфрак санап калган. Шүрәле бик җитез икән: ботактан ботакка маймыл кебек сикереп йөри, яфрактан яфракка тиеп барган озын бармакларына күз дә иярми икән. Ул санап бетергән дә Айсылу артыннан торып чапкан.

Шулвакыт кызның хәтеренә әбисе сөйләгән хәйлә килеп төшкән. Имеш, аяктагы башмакларның алдын артка кисәң, Шүрәле кире якка торып чабачак... Айсылу шулай эшләгән: башмакларын кирегә киеп, чатанлап булса да юлын дәвам иткән.

Чынлап та, Шүрәле Айсылу аяк киемен алыштырган урынга килеп җиткән дә: «Бу кыз кире киткән икән», — дип, үзе чабып килгән якка китеп барган.

Ләкин Шүрәле үзенең алданганлыгын тиз аңлап алган. Тагын Айсылуны куа башлаган. Йөгерә торгач, кызның хәле бетә башлаган. Инде егылдым,

росший посреди поляны могучий дуб, — и лишь потом отправляйся искать... И смотри у меня — не жульничай! — пригрозила напоследок Айсылу.

Девушка скрылась в чаще леса, а Шурале остался пересчитывать листву. Пока он усердно пересчитывал, Айсылу успела отбежать на значительное расстояние. Но и Шурале проворен: словно обезьяна, скакал он с ветки на ветку, длинные пальцы его столь стремительно порхали от листка к листку, что глаза не успевали уследить за ними. Вот он пересчитал все листья и ринулся вслед за Айсылу. В эту минуту ей вспомнилась одна хитрость, о которой рассказала бабушка. Якобы если надеть обувь пятками вперёд, то и Шурале побежит в обратную сторону... Так Айсылу и поступила: надела обувь пятками вперёд и, хромая, спотыкаясь, продолжила движение.

И правда, Шурале подбежал к тому месту, где Айсылу «переобулась», и решив: «Девушка-то в обратную сторону пошла», — пустился туда, откуда прибежал.

Однако Шурале быстро понял, что его обманули. Опять стал нагонять Айсылу. Через некоторое время она выбилась из сил. «Ну всё, пропала я, в лапы Шурале попала», — думала Айсылу, как вдруг услышала журчание ручья, текущего где-то неподалёку. Она бегом отправилась туда. Ещё одно наставление бабушки вспомнилось ей: «Шурале боится воды!»

беттем, Шүрәле кулына килеп каптым дигәндә генә, ул якында инеш суы чылтыравын ишетеп алган. Йөгереп шунда барган. Әбисенең тагын бер сүзе исенә төшкән: «Шүрәле судан курка!»

Менә ул, соңгы көчен җыеп, инеш аркылы сикереп чыккан. Инде тотам-тотам дип сөенеп килгән Шүрәле инешнең теге ягында торып калган. Үзе Айсылудан ялварыпмы-ялвара, үтенепме-үтенә, ди:

— Әйт инде, кызым, бу инешнең башы кайсы якта икән, ә?

Кыз инешнең түбәнге ягын күрсәткән:

— Әнә теге якта ул, абзый кеше!

Шүрәле сөенә-сөенә инешнең түбәнге ягына йөгергән, Айсылу — үз юлына. Тик ул һаман авылга алып чыга торган сукмакка төшә алмый икән.

Шүрәле бу вакытта, инеш башын эзләп, диңгезгә кадәр барып җиткән, аннары, үзенең алданганын аңлап, кабат урап килгән. Тапкан да әйткән:

— Син, кызый, бу юлы инде бернинди хәйлә белән дә котыла алмассың! Кытыклап үтерәм мин сине хәзер!..

Айсылуга башка чара калмаган. Йөзен куллары белән каплап, ачы күз яшьләре белән еларга керешкән. Әмма аның бу күз яше генә ачулы

Вот она, собрав остатки сил, перепрыгнула через ручей. Обрадованный скорым обладанием добычи, спешащий Шурале остался по ту сторону ручья. Он упрашивал, умолял Айсылу:

— Скажи уж, дочка, откуда начинается этот ручей, а?

Девушка ткнула в другую сторону:

— Вон оттуда он начинается, Шурале-абзый!

Шурале радостно поскакал в противоположную к истоку сторону.

Айсылу пошла своей дорогой. Но она по-прежнему никак не могла отыскать тропинку к дому.

Шурале в это время домчался до самого моря в поисках истока ручья, и тогда, поняв, что его обманули, вернулся на прежнее место. Он быстро нашёл девушку и сказал:

— Ты, девка, не проведёшь меня больше, не избавишься никакой хитростью! Защекочу тебя сейчас до смерти!..

Айсылу оказалась в безвыходном положении. Закрыв лицо ладонями, она заплакала горючими слезами. Но эти слёзы не растопили сердце жестокого Шурале. Вот он, выставив вперёд длинные, безобразные, волосатые руки, шевеля узловатыми пальцами с отросшими ногтями, приближался к девушке. В эту секунду Айсылу разглядела удивительную

Шүрәленең күңелен эретә алмаган. Менә ул озын, килбәтсез, йонлач кулларын баш очына күтәреп, җиту тырнаклы бармакларын алга төбәп, кыз өстенә килә башлаган. Шунда Айсылуның яшьле күзе бер галәмәткә юлыккан. Шүрәленең култык асты шыр тишек, имеш! Шул тишек аша бөтен эчке әгъзалары күренеп тора, ди!

Шүрәле Айсылуга якын ук килеп, кытыклый башлады дигәндә генә, Айсылу үз кулындагы очлы таягын аның култык астына тыгып җибәрмәсенме!

— Ай! Хараплар гына иттең, чукынчык кыз! Ай! Үтердең!.. Бетердең!.. — дип, Шүрәле үрле-кырлы сикеренергә тотынган.

— Әгәр мине урман читенә чыгарып куйсаң, таягымны тартып алам, чыгармасаң — эчеңне тишәм! — дип янаган кыз.

Шүрәле кызны урман читенә чыгарып куйган. Саубуллашканда:

— Исемең ничек соң синең, кызый? — дип сораган.

— Минтиле була минем исемем, абзый, онытма — Минтиле! — дигән.

Беркатлы Шүрәле Айсылуга ышанган. Соңрак башка шүрәлеләр: «Ни атлы кыз синең кулдан ычкынды соң? Кем алдады сине?» — дип сораганда, «Минтиле», — дип җавап бирә торган булган.

штуку. Подмышка Шурале — сквозная дыра! Из этой дыры видны якобы все внутренние органы!

Шурале, вплотную приблизившись к Айсылу, собрался было начать щекотать её, но девушка со всего размаху всадила в эту дыру палку, которую держала в руке!

— Ай! Угробишь ведь, проклятая девчонка! Ай! Убила!.. Погибаю!.. — принялся скакать и вопить Шурале.

— Если выведешь меня на край леса, выдерну палку, не выведешь — проткну тебе брюхо! — пригрозила она.

Шурале вывел девушку на край леса, к началу тропинки в деревню. Когда прощались, он спросил у Айсылу:

— Как тебя зовут-то, девица?

— Ятупица меня зовут, не забудь, абзый, Ятупица! — ответила она.

Все мы увидели и узнали, какой простофиля Шурале. Когда впоследствии другие шурале спрашивали его: «Как звали ту девушку, которую ты упустил из рук?» — Он отвечал: «Ятупица». И его соплеменники разражались громким смехом, подзуживая: «Мы и так знаем, что ты тупица, можешь лишний раз не говорить».

# ЕЛАН. АЖДАҺА
## ЗМЕЙ АЖДАХА



«Елан патшасы Шаһмара», «Ярлы егет белән патша кызы», «Ак елан», «Зөһрә» әкиятләре (0+)

Сказки «Шахмара», «Бедняк и царевна», «Белый змей», «Зухра» (0+)

Ибне Фадлан, Елан болгарларда озын гомер (үлемсезлек) һәм акыл-зиһен символы буларак каралган, дип яза. Елан рәвешендәге беләзекләр, башка бизәнү әйберләре, чүлмәкләрдәге, аеллардагы сурәтләр — моның ачык мисалы. Чынлап та, төркиләрдә Елан символына гадәттән тыш көч салына. Ул кешегә генә түгел, Күк тәңрегә дә буйсынмый, имеш.

Елан татар әкиятләрендә, миф-ышануларында һәм тискәре, һәм уңай образ буларак тасвирлана. Сүз дә юк, уңай тип еланнар күбрәк очрый. Уңай, ак (сары) еланнар нигездә кешегә карата ике төрле изгелек эшлиләр: бүләк бирәләр һәм ярдәм итәләр. Тискәре тип еланнар күпчелек очракта — эпизодик персонажлар гына, һәм алар асылда сакчы вазифасын үтиләр.

Төрки мифологиядә бер кызык бүленеш бар. Еланнар, күпме гомер яшәүләренә карап, төрлечә аталып йөртеләләр һәм, хәтта төрле рәвешләргә керәләр. Мәсәлән, бер елдан сигез елга кадәр яшәүче еланнар «Хәят» дип аталалар. Сигез яшьтән йөз яшькә кадәр яшәүче еланнар «Әфгый» дип йөртелә. Йөз яшьтән мең яшькә кадәр еланнар Аждаһа гомере белән яшиләр.

*Яков Коблов:*

Что касается змея, прожившего более 100 лет и называемого Аждага, то этот змей отличается необыкновенной силой. Вот что рассказывается о силе этого дракона. Один мулла со своим семейством пошёл косить траву. Когда мулла докосил свой прокос и хотел возвратиться обратно, чтобы закосить второй прокос, он услышал в камышах около болота большой шум. Мулла, взявши вилы, пошёл на этот шум и вдруг видит в камышах пребольшущего змея, который стал притягивать к себе муллу воздухом. Как мулла ни сопротивлялся, его притягивало воздухом прямо в пасть змея. Тогда он уставил в пасть вилы. В таком положении мулла держался несколько времени. Но затем змей обернул муллу своим хвостом и задавил его, хотя и сам околел, раненный вилами.



*Лонг — Вьетнам аждаһасы.*

*Лонг — вьетнамский дракон.*

Аждаһаны күпчелек очракта яшел, кытыршы (елан) тәнле, өч, җиде, унике башлы, алга чыгып торган кызгылт күзле, озынча борынлы, ләкин елан яки ерткыч җанвар чырайлы, озын кызыл телле, кош тәпиле, үткен тырнаклы, озын койрыклы, кайчакта башында бер йә ике мөгезе (аны таҗ дип тә карарга мөмкин) булган, авыз-борыныннан утлы сулыш өреп торган зур килбәтсез гәүдәле явыз, хәшәрәт зат итеп сурәтлиләр.

Аждаһа, гадәттә, нинди дә булса авыл яисә шәһәргә һөҗүм итә; халыкны, илне коткарып калу өчен, аңа көн саенмы, ел саенмы иң гүзәл кызны корбанга бирәләр. Еш кына ул патша кызы була. Икенче бер очракта гүзәл кызларны Аждаһага иген мул уңсын, ил имин булсын өчен бирәләр.



*Цин-Лун — Кытайда яшел төстәге аждаһа.*

*Цин-Лун — китайский лазурный дракон.*

Змей Аждага редко встречается в населённых местах. Это происходит от того, что столетнего змея, только что превратившегося в Аждага, по повелению Всевышнего Творца, обыкновенно поднимает облако и уносит на какой-либо дальний остров, находящийся в Великом океане (Мухит дингез), где дракон и живёт 1000 лет. Некоторые заявляют, что видели, как дракон бьёт своим хвостом, когда несётся по воздуху на остров. Такой участи подвергаются только те Аждага, которые немало наделали бед народу.

# ЗИРӘК БАТЫР ҺӘМ АЖДАҺА

Тау итәгендәге бер авылда Зирәк исемле егет яшәгән. Авылдан ерак та түгел бер төпсез күл бар икән. Ярларына кеше заты якын килми торган бу Каракүл дигән сулыкта өч башлы хәшәрәт елан — Аждаһа яши, ди. Ул елга бер мәртәбә кешеләрдән сылу кыз таләп итә икән… Бу кызлар Аждаһа биләмәләрендә аның хатыны яки хезмәтчесе булып яшиләр, ди.

Авылның ир-егетләре күп мәртәбәләр бу Аждаһага каршы алышка чыгып караганнар. Ләкин берсе дә җиңә алмый икән. Сәбәбе бик гади — алар Аждаһаның җаны кайда икәнен белмиләр, ди.

Менә чират Зирәкнең сөйгән кызы Майяга җиткән. Өч көннән авыл халкы Майяны Аждаһа яши торган Каракүл буена илтеп куярга тиеш икән. Шунда Зирәк:

— Әгәр Аждаһаның башына җитмәсәм, исемем Зирәк булмасын! — дигән.

Егет шул сәгатьтә үк юлга кузгалган. Тирә-якта акылы, зирәклеге белән дан казанган аксакал янына барып:

— Бабакай, сөйгәнемнең язмышы куркыныч астында. Миңа, аны коткарыр өчен, Аждаһаның җанын алырга кирәк. Әйт әле, ул хәшәрәтнең

# ЗИРЯК-БАТЫР И АЖДАХА

В одном ауле, что располагался у подножия горы, жил парень по имени Зиряк. Недалеко от аула было чёрное бездонное озеро. Люди не приближались к берегам Каракуля, где жил трёхголовый змей — Аждаха. Крестьяне должны были раз в год приносить в жертву Аждахе самую красивую девушку… Во владениях змея эти девушки становились или его жёнами, или наложницами.

Джигиты этого села не раз выходили биться со змеем. Но никому из них не удалось победить. А причина этих неудач проста — не знали они, где находится смерть Аждахи.

Вот наступила очередь возлюбленной Зиряка — Майи. Через три дня жители села должны привести Майю к берегу Каракуля. Тогда Зиряк сказал:

— Если не одолею Аждаху, то звать меня не Зиряк! За три дня я узнаю, где находится смерть Аждахи, а вы пока не отводите мою невесту к этой гадине…



җаны кайда була? — дип, киңәш сораган.

Аксакал уйланып торган да әйткән:

— Әгәр син минем сүзгә тапкыр җавап бирә алсаң, әйтермен, — диган. Зирәккә күз йомып торырга кушкан да бер күбәләк тотып, уң учына салып, артык кысмыйча гына бармакларын йомган...

— Йә, ач күзләреңне!

— Тыңлыйм, бабакай...

— Менә минем учта — бер күбәләк. Йә әйт: тереме ул, үлеме?

Зирәк үзен уч төбендә яткан күбәләк кебек хис иткән. Аның

Парень в ту же минуту отправился в путь. Добрался он до избы самого мудрого аксакала во всей округе.

— Дедушка, жизнь моей возлюбленной под угрозой. Чтобы спасти её, мне нужно одолеть Аждаху. Скажи-ка, где находится смерть у этой гадины? — спросил Зиряк.

Немного подумав, аксакал ответил:

— Скажу, если найдёшь мудрый ответ на мой вопрос, — молвил старец. Затем он попросил Зиряка на несколько секунд закрыть гла-



язмышы — шушы учның кысылу-кысылмавында... Әгәр егет «тере» дип әйтсә, карт аңа күбәләкне кысып, үтереп бирәчәк, «үле» дисә, учын ачып, күбәләкне күккә очырып җибәрәчәк... Ниһаять, егетнең җавабы әзер булган.

— Күбәләкнең үле яки тере булуы, бабакай, синең кулыңда. Аның бөтен язмышы синең кулда... — дип җавап биргән Зирәк.

Аксакалга җавап ошаган. Ул егеткә Аждаһаның серен ачкан: аның җаны койрыгында икән! Ләкин аны бер генә тапкыр чабарга мөмкин, ди...

Егет әйләнеп кайтканда, Майяны Аждаһага бирергә әзерләнгән булалар инде. Каракүл янындагы тауда кайгылы башын иеп басып торган сөйгәне алдына килеп баса Зирәк. Шулвакыт күлдән давыллы өермә булып өч башлы Аждаһа күтәрелә дә, очып килеп, Зирәк каршына төшә.

— Йә, кайда миңа дигән гүзәл кыз? — дип җикеренә ул.

Шулвакыт Зирәк аңа, кылычын күтәреп:

— Алыштанмы, бирештәнме? — ди.

Аждаһаның ачуы чыга. Ул шундук канатларын як-якка җәеп, кабарынып килә дә, сулышы белән суырып, Зирәкне кабып йота. Халык аһ итәргә дә

за. Аксакал тем временем поймал бабочку, положил в правую руку и несильно сжал пальцы...

— Ну, открой глаза!

— Слушаю тебя, дедушка...

— В моей горсти бабочка. Ответь: жива она или мертва?

Зиряк представил себя на месте бабочки. Его жизнь зависела бы от силы сжатия кулака... Если парень скажет «жива», старец плотнее сожмёт кулак и вручит мёртвую бабочку, если скажет «мертва», то разожмёт пальцы и выпустит пленницу в небо... Наконец ответ был найден.

— Состояние бабочки в твоих руках, старец. Её жизнь целиком зависит от тебя... — ответил Зиряк.

Ответ понравился аксакалу. Он открыл Зиряку секрет Аждахи. Смерть этого громадного змея находится в его хвосте. Но рубить нужно всего один раз...

Когда Зиряк вернулся домой, Майю уже собирались отдать Аждахе. Парень подошёл к опечаленной возлюбленной, стоящей у склона горы

өлгерми кала. Әмма, Аждаһа йотканда, Зирәк кылычы белән аның бугазын ярып чыга. Чыга да өч башын да чабып өзә. Җаны исән калган Аждаһаның башлары тагын үсә. Зирәк, тагын бер селтәнеп, Аждаһаның җаны яшәгән койрык очын чаба. Аждаһа гөрселдәп җиргә егыла. Зирәккә әйтә:

— Син җиңдең... Үтенәм синнән: җаным тизрәк кыелсын өчен, тагын бер тапкыр койрыгыма чап, мине болай мәсхәрә итеп, үләксә хәлендә калдырма...

Ләкин инде Зирәк белә: җан яшәгән урынны бер генә тапкыр чабарга ярый. Икенче чапса, Аждаһа яңадан терелячәк.

Аждаһаның хәйләсен аңлаган батыр егет аның чабып ташланган койрыгын шунда гына очып йөргән козгыннарга ташлый да хәшәрәтнең гәүдәсен кыядан Каракүлгә этеп төшерә. Аннары Майя янына ашыга...

рядом с озером. В этот миг над водной гладью огромным смерчем взмыл трёхголовый змей и опустился напротив Зиряка.

— Где положенная мне красавица? — заорал он в три глотки.

— Ну что, поквитаемся?! — обнажил и поднял над головой свой меч Зиряк.

Аждаха разозлился. Он тут же, раскрыв крылья, вздыбившись, всосал в себя Зиряка и проглотил. Народ даже ахнуть не успел. Но Зиряк пропорол мечом желудок Аждахи и вышел наружу. Вышел и отрубил три головы змею. Но Аждаха не умер, и головы выросли заново. Тогда Зиряк ещё раз размахнулся и рубанул по хвосту Аждахи, где находилась его смерть. Аждаха с грохотом упал на землю и сказал Зиряку:

— Ты победил... Прошу тебя об одном: не мучь меня, добей, ударь ещё раз по хвосту, не оставляй на поругание...

Но Зиряк уже знал: хвост можно рубить только один раз. Если рубануть второй раз, то Аждаха оживёт.

Разгадавший хитрость Аждахи парень бросил отрубленный хвост находящимся поблизости воронам, а обмякшее, находящееся при смерти тело змея столкнул в Каракуль. Затем поспешил к Майе...

# ЮХА



«Аучы» әкияте, Р. Батулла: «Тавышсыз курай» (0+)

Сказка «Охотник», Р. Батулла: «Безмолвный курай» (0+)

Ышанулар буенча, еланнар мең елдан соң Юхага әйләнә. Юха елан кешегә һәм хайванга әверелү сәләтенә ия. Шушы сәләте аркасында ул гүзәл кыз кыяфәтенә керә һәм, батыр егетләрне гашыйк итеп, юхаланып, үзенә өйләндерә.

Юхага өйләнгән ирнең тормышы җәһәннәмгә әверелә; ахырдан «хатыны» аны буып үтерә яки терелəй кабып йота... Ә Юханың үзен үтерү мөмкин түгел. Аңардан бары тик сусыз җирдә бикләп калдырып яисә эссе мунчага ябып кына котылып була.

Шулай да, Юха-кызны ничек танып була соң? Беренчедән, Юханың авызыннан һәрвакыт үләксә исе килеп тора; икенчедән, Юханың кендеге булмый; өченчедән, Юха күп су эчә, ул сусыз бер минут та тора алмый. Юха, кеше кыяфәтендә кырык тугыз көн яшәгәч, кабат Аждаһага әверелә.



*Наг — индусларда ярымкеше, ярымъелан.*

*Нага — положительный мифологический персонаж у индусов.*

*Яков Коблов:*

...По истечении 1000 лет Аждага превращается в Юху, которая имеет способность превращаться в человека и животных и в таком виде являться татарину. Юха (...) крайне опасна и (...) превращается в красивую девицу, на которой татарин может даже жениться, влюбившись в неё. Но Юха-девица непременно причинит вред своему мужу или даже может съесть его. (...) Есть некоторые признаки, по которым Юху-девицу можно отличать от настоящей девицы: 1) у Юхи всегда изо рта пахнет падалью; 2) у Юхи не бывает пупа; 3) у Юхи всегда большая потребность в воде. При этом Юха (...) существует на свете только 49 дней, потом она опять превращается в Аждага...



*Ехидна — грекларда ярымкеше, ярымъелан, бөтен явызлыкның әнкәсе, диелә.*

*Эхидна — получеловек, полузмея у греков, прародительница всего злого.*

# ЮХАНЫ ЮХА ҖИҢӘ

Камәр исемле егет су буеннан бик чибәр бер кыз ияртеп кайта. Ул төшкәндә, теге кыз елап утыра икән. «Мин — ятимә, үги әниләрем ташлап калдырды, адаштырдылар, хәзер нишләрмен инде...» — ди икән. Чибәрлеге күзнең явын алырлык, ди. Тик нигәдер сөйләшкәндә авызын каплап сөйләшә, үзе оялчан — күзгә дә тутырып карый алмый, ди...

Әтисе бик яшьли суга батып үлгәч, анасы белән генә яшәгән Камәр, бу ятимәне кызганып, үзләренә алып кайта, алай гына да түгел, аңа үлеп гашыйк була...

Яшьләр гаилә корып яши башлыйлар. Мәхәббәттән исергән егет баштарак хатынындагы сәерлекләргә игътибар итми, бераздан төшенә башлый: бу хатын — ниндидер серле зат. Ул нигәдер егетнең анасы белән сөйләшми, аны күрсә, тизрәк эчке бүлмәгә, чыбылдык эченә кереп китә. Килен кеше төннәрен берничә мәртәбә су эчәргә тора, кайчакта хәтта урамга чыгып, коедан су алып коена... Иң мөһиме, ул киенеп йоклый, чәчен тарамый, авызын каплап йөри...

# ЮХА БЬЁТ ЮХУ

Татарин по имени Камар привёл с озера прекрасную девушку. Когда он встретил её у воды, та горько плакала. «Я сирота, мачеха, сбив с дороги, бросила меня здесь, как же мне быть...» — причитала она.

Красоты она, говорят, была неописуемой. Но почему-то при разговоре прикрывала рот, стеснительная — прямо в глаза не могла посмотреть...

Живущий только с матерью парень, отец которого утонул, когда Камар был совсем маленьким, пожалел сироту и привёл к себе, и не только привёл, но и влюбился в неё без памяти...

Молодые стали жить семьёй. Опьяневший от любви парень поначалу не замечал некоторых странностей жены, но позже прозрел: эта женщина весьма странная личность. Она почему-то не разговаривает с его матерью, если завидит её, сразу прячется на своей половине. По ночам невестка по нескольку раз встаёт пить, иногда даже выходит на улицу, набирает воды из колодца и обливается... Самое необычное, она спит в одежде, не расчёсывает волосы, прикрывает рот...



Бер кичне, хатыны йоклап киткәч, Камәр хатынының өстен ачып ташлый. Һәм аһ итә: хатынының кендеге юк laса! Тәне елан тиресе кебек елкылдап тора, кытыршы... Йөзенә якынрак килсә, гайрәте чигеп, читкә тайпыла, — хатынының авызыннан сасы исләр килә...

Шулвакыт, нидер сизенеп, хатыны уянып китә һәм ал төстәге шардай күзләре белән Камәргә төбәлә... Зәһәр чәчеп торган бу күзләрне күргәч, ир кеше барысын да аңлый: гүзәл кыз булып өйләренә килеп кергән Юхадан котылу булмаячак!.. Ул, барлык белгән догаларын исенә төшерергә тырышып, үлемгә әзерләнә...

Бу вакытта инде Юха-кыз Кара елан рәвешенә кереп өлгергән була. Менә ул, сасы авызын ачып, йотар өчен, Камәргә якынлаша... Камәр, үзе дә сизмәстән: «Анакай, коткар!» — дип кычкырып җибәрә.

Шулвакыт Камәрнең әнисе йоклый торган чыбылдык артында нидер шапылдап идәнгә төшә, шап-шоп килеп йөри башлый, шунда ук бүрәнә сөйрәгән, җил сызгырган, елан ысылдаган тавышлар ишетелә... Елан булып йотарга килгән Юха Камәрне суырып алдым дигәндә, чыбылдык ар-

В одну из ночей, дождавшись, когда жена уснула, Камар скинул с неё одежды. И ахнул от удивления: у жены не было пупка! Кожа блестела, словно змеиная, была шершавой и чешуйчатой... Приблизившись к лицу, он в ужасе отпрянул, — изо рта жены исходило чудовищное зловоние...

В этот миг, словно что-то почуяв, проснулась жена и уставилась красными шарами глаз на Камара... Эти вылупленные красные шары глаз всё объяснили Камару: ему не избавиться от зловещей Юхи, проникнувшей в дом, обернувшись красавицей!.. Читая все известные молитвы, он приготовился к смерти...

А Юха-девушка в это время обратилась в Чёрную змею. Вот она, открыв вонючую пасть, приближается к Камару, чтобы проглотить его... Камар невольно вскрикнул: «Мама, помоги!».

Тут же с половины, где спала мать Камара, раздался грузный шлепок падения, звуки шагов, одновременно послышались завывания ветра и змеиное шипение... Юхе оставалось лишь пошире раскрыть пасть и проглотить Камара, как из-за занавески материнской половины выползла ещё более огромная, более страшная Юха! Вот она посмотрела на Камара, затем перевела взгляд на Юху-жену и, обвив невестку хвостом, принялась

тыннан тагын да зуррак, тагын да гайрәтлерәк елан килеп чыкмасынмы?! Менә ул бер Камәргә, бер Юха еланга карап ала да хатын-еланны койрыклары белән бөтереп-бөтереп буа башлый... Юха аһ итә дә алмый хәрәкәтсез кала. Мәһабәт елан исә ишеккә бәрелә-сугыла тышка чыгып китә һәм якындагы елгага ташлана...

Таңда Камәр үз анасын яр буенда хәлсез-буынсыз яткан хәлдә табып ала. Ул инде газиз әнисенең дә кайчандыр Юха-кыз булып әтисенә кияүгә чыгуын, гомер буе Юха да, кеше дә була алмыйча интегеп, авырып яшәвен, әтисенең ни өчен суда батып үлүен, иң мөһиме, үзенең әнисе аркасында гына исән калуын аңлап-төшенеп алган була...

душить... Младшая Юха, даже не в силах вздохнуть, обмякла и перестала сопротивляться. Огромная змея, выбив дверь, утащила Юху-невестку на улицу и утопила в реке...

Утром Камар обнаружил свою маму на берегу реки, обессилевшую, с переломанными конечностями. Теперь-то он понял, что в своё время его отец женился на Юхе, которая всю жизнь мучилась от того, что не могла стать обыкновенным человеком, и почему утонул его отец, но самое главное, он понял, что остался в живых лишь благодаря матери...



## Tatar mythological characters

**Barn and house spirit** (does not have a specific name)



This house spirit is usually supposed to look like an old man below average human height. It is humpbacked with pale wrinkly face, big eyes and long grey hair and sometimes he has a beard and mustache. It is dressed in white clothes made of hemp canvas and they say, in some cases it wears a cone-like hat. A house spirit lives mostly under the floor and does not contact humans.

A household spirit is a positive character. It is considered to protect the house and those living in it. Though, there is a condition for gaining the protection: there must be peace and harmony in the house. This spirit does not like the black color and hates black cats especially. White cats, on the contrary, are sure to have a long and peaceful life in the house where a house spirit dwells.

**Bichura** (another type of a house spirit)



Bichura is a Tatar folklore character with waistless body of about one meter (3.28 ft.) height. It is dressed in a reddish shirt and orpek — old traditional woman head cover — with grey hair seen from beneath. Its face is frighteningly old and wrinkly, soiled with coal and dust. They say that its coal-black dot-like eyes sometimes burn like small pieces of coal.

Traditional places where Bichura lives are dark corners and small dark rooms inside the house. This spirit is especially fond of brooms leaned against the wall in room corners. It often lives behind these brooms or together with a broom in a dark closet. Bichura likes riding a broom.

Bichura does not like cleanness; therefore, it chooses dirty and messy houses. It is not afraid of humans and can appear in the house even when people are not yet asleep. It is quite noisy at night and can start sweeping the floor or moving pots and pans all of a sudden.

**Water spirits**



There are a few water spirits in the Tatar folklore: Su babasi (literally «water grandfather»), Su iyase (lit. «water inhabitant») and Su anasi or Su qizi (lit. «water mother» or «water girl»).

Su babasi («water grandfather») likes loneliness and lives in the most remote parts of lakes and swamps. In some cases it is described as a dwarf and in other cases as a supernatural stately creature. Its appearance is described like this: greenish face, reddish eyes, algae instead of hair and fish scales instead of clothes.

Su iyase («water inhabitant») is mainly pictured as a human-like good-looking young man. It has a human face with round bulging eyes

and long black or red hair. In oral tales this water spirit is said to be half fish and half human.

Su anası («water mother») is a spirit described as a human-looking female creature with svelte body, big oblong head, thick black hair reaching the ground in its length, big black bulging eyes and light pink skin.

### Albasti, Albasty



Dark forces and evil spirits that live in uninhabited houses, abandoned places, fields and next to pits are used to be called Albasty. These spirits can look like a human, a horse cart, a haystack and even a fir tree, and it can change its appearance.

Albasty from Tatar mythology tortures humans by stifling them while sleeping. It lies down on a sleeping human and starts pressing down to stop his breathing. Sometimes it drinks human blood to gain more power. They say that shedding Albasty's blood should be avoided because every drop of its blood produces a new evil spirit.

Albasty can also look like an old female with reddish skin or clothes, messed up hair, round eyes and sharp nose. Unlike humans, Albasty does not have any skin on its back and this makes all its organs visible.

Albasty is dangerous only at night because it disappears once the crow of morning roosters is heard.

### Ubir, Ubyr (Vampire)



An Ubyr in Tatar folklore myths is pictured in two main ways. The first one is a human-like Ubyr. It has a glowing sphere-like head with burning coals instead of eyes and a thin and long tail that looks like a greenish blue flame. Ubyr is also pictured as a sphere of light that rolls on the ground at night. The reason why Ubyr resembles fire is not coincidental. Just like fire burns and destroys everything on its way Ubyr also gobbles up everything it encounters. It likes to eat rotten and putrid flesh especially.

Ubyr is able to change its appearance anytime it wants to and turns into a dog, a cat or a pretty girl. It can even turn into a four-legged creature with human legs, arms and with a pig face to scare life out of people.

### Ubirli qarchiq (Ubyrly Qarchyk, Witch)

A witch usually lives in secluded places far away from people. A witch does not differ from other old ladies but is always wearing black clothes.

According to early Turkic myths, meeting a witch is the same as meeting your death. A witch does not only torture people but also stifle them, drink their blood, send diseases and put the evil eye on them.

Another evil act of a witch is swallowing people up. Sometimes she swallows a person and then spits him up. A human spat up by the witch returns to this world as a completely different person. He can become a better version of himself or turn into an evil creature.

Some oral tales and folklore myths contain information about witches not only harming people but also helping them.



### Yalmawiz, Yalmawyz

A Yalmawyz lives far away from human settlements in dark forests or mountain caves. It stays away from human settlements and villages and keeps an eye on villages located next to the areas of its habitat. If Yalmawyz chooses a village and casts a spell on it, this village starts to face decrease in development, wealth, harvest and population and eventually disappears. The reason of such decrease is because all the goods are being eaten up by Yalmawyz.



In Tatar mythology a Yalmawyz is described as an ugly old woman with massive rotund body, big belly, snake tail, big single bulging eye, big mouth with thick lips and long snake-like tongue. When a Yalmawyz walks over the ground, it causes storms and gales. This creature is so big that it can sweep away everything around at the distance of seven kilometers (4.35 miles) with its extremely long tongue and swallow everything up. It is said that a Yalmawyz breath is very toxic, and its single whiff is enough to make a human faint. Legends say that a Yalmawyz uses its breath to make people faint and then eats them.

### Ghost

People believe that ghosts are the lost souls of people who died of unnatural reasons. They haunt the places where blood of murdered people is shed or the graves of those people. In Tatar folklore ghosts are usually seen quietly walking around covered with long white clothes. But sometimes they are heard to be crying and moaning, or singing songs with a strident voice. A ghost is described as tall and slim, only its pale face seen from its shroud.



Ghosts do not harm people, but they can frighten those alive by unexpected appearing in front of them at night, following them or by producing scary crying and moaning.

### Diyu, Div (Daeva)

A Div is a supernatural entity that originally came from Persian or Iranian mythology. There are many different ways Divs are being pictured. Sometimes they are described as creatures with one or a few heads, a single eye, naked, with hairy body. They are also said to have anthropomorphic features, being dressed in old clothes, having long arms and long fingers with very hard, iron-like nails. Divs are believed



to live in groups in their own kingdoms. Those kingdoms are said to be located behind the mountains, under the ground or in the underwater world. The entire life and activities of these creatures are related to underground treasures and wealth.

Though Divs are underground creatures there are oral tales saying that they sometimes come out of their kingdoms and walk about in the human world, and in rare cases they kidnap beautiful girls. There is also a legend saying that Divs often invite lonely travelers into their underground houses and palaces and offer them a wide range of eats and drinks. People who try them stay in a Div's kingdom to serve forever. It is believed that saying «bismillah» (lit. «with the name of Allah») repeatedly is the way to get rid of these creatures. A Div that hears «bismillah» disappears immediately and its eats and drinks turn into horse excrements.

### **Shurale** (a forest spirit)



Shurale looks like a human but he has longer arms and about 13 centimeters-long (5 inches) fingers. He is also said to have a slightly hairy body, small head, a beard and mustache, sharp nose, big bulging eyes, long ears and sometimes a small horn on his forehead. They often say that Shurale walks with a stoop.

There are two features of Shurale that are always mentioned: he makes people get lost and then tickles them to death. However, this forest spirit makes only lonely people lose their way. If there are two people or a single person with a dog, Shurale will not approach them.

### **Snake and Dragon**



Snakes are shown as both positive and negative characters in Tatar myths and fairytales. White or yellow snakes are basically believed to give people two types of services: give them presents and help. Snakes in negative light are usually shown only as episodic characters that serve as a guard or a keeper of something. When a snake gets a hundred years old it becomes a Dragon.

A dragon in most cases is described as a creature with stately body, green and rough skin, multiple heads, sometimes with one or two horns on them, bulging reddish eyes, long red tongue and long tail. It is also said that a dragon face resembles a face of a snake or a predatory animal, its feet look like bird feet with sharp claws, and flame is seen from his nose and jaws while breathing.

There is an interesting belief that this creature can only be hit once and if a warrior hits a Dragon, cuts off his head and then touches it again, the Dragon comes to life.

## Yuha

A thousand year-old snake becomes Yuha. A Yuha snake has an ability to change its appearance and look like a human or an animal. Because of this ability, a Yuha turns into extremely beautiful girl and makes young men fall in love and marry her. A Yuha sometimes sets conditions to her future husbands not to watch her combing her hair and not pat her on the back. Those breaking the rules get frightened by seeing their wife detach her head from the body while combing her hair or noticing scales on her back. Their life eventually turns into the hell, and finally a Yuha strangles them or swallows them alive.



A Yuha is described as having putrid breath and no navel, and drinking too much water. The reason this creature wants to get married is to swallow its husband. If it fails to do so within forty-nine days, a Yuha turns back into a Dragon and flies away.

A Yuha that turned into a girl does not always live as a human, it is said that she becomes a snake when her husband falls asleep and likes to return to its natural habitat and spend nights next to lakes and rivers. In old days, if people saw a big black snake next to the river at night they used to realize that a Yuha settled in their village and started looking for ways to find and catch it. It is believed that the only way to kill a Yuha is to lock it in a hot sauna.

| ЭЧТӘЛЕК | | СОДЕРЖАНИЕ |
|---|---|---|


| | | |
|---|---|---|
| *Мифлар каян барлыкка килгән?* | 3 | *Откуда появились мифы?* |
| Өй иясе | 4 | Домовой |
| Бичура | 12 | Бичура |
| Су бабасы. Су иясе. Су анасы | 18 | Водяной дед. Водяной хозяин. Водяная |
| Албасты | 26 | Албасты |
| Убыр | 32 | Убыр (Оборотень) |
| Убырлы карчык | 40 | Убырлы карчык (Баба-яга) |
| Ялмавыз | 48 | Ялмауз |
| Өрәк | 54 | Уряк (Призрак) |
| Дию | 60 | Див |
| Урман ияләре. Шүрәле | 66 | Шурале |
| Елан. Аждаһа | 76 | Змей Аждаха |
| Юха | 84 | Юха |
| Tatar mythological characters | 90 | |

Литературно-художественное издание

Автор-составитель **Гильманов** Галимзян
(**Гильманов** Галимьян Хамитьянович)

**ТАТАРСКАЯ МИФОЛОГИЯ ДЛЯ ДЕТЕЙ**

Казань. Татарское книжное издательство. 2018

*На татарском и русском языках*

Әдәби-нәфис басма

Автор-төзүчесе **Гыйльманов** Галимҗан Хәмитҗан улы

**ТАТАР МИФЛАРЫ — БАЛАЛАРГА**

Мөхәррирләре *А. Ф. Галиәхмәтова, Э. Р. Хөснетдинова*
Бизәлеш мөхәррире *Р. Х. Хәсәншин*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы *Н. А. Казакова*
Корректорлары *А. Р. Миңнуллина, И. И. Галиева*

6 + Знак информационной продукции согласно ФЗ от 29.12.2010 г. № 436 — ФЗ.

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 06.12.2018.
Форматы 84×108 $^1/_{16}$. Шартлы басма табагы 10,08. Тираж 1000 д. Заказ

«Татарстан китап нәшрияты» ТР ДУП. 420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.
Тел./факс: (843) 519-45-22.
**http://www.tatkniga.ru**
**e-mail: info@tatkniga.ru**

**Татарстан китап нәшриятының фирма кибетләре:**
Казан, Бауман урамы, 19. Тел.: (843) 294-70-50.
Казан, Бауман урамы, 51. Тел.: (843) 225-76-55.
Казан, Декабристлар урамы, 2. Тел.: (843) 519-45-13.

**Маркетинг бүлеге:**
Казан, Декабристлар урамы, 2. Тел.: (843) 519-45-35.

**Интернет-кибет: http://www.tatkniga.ru**

«Татмедиа» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.

